КҮПМЕ ТҮЛИСЕ?

«ВТ» хәбәрчесе автомобиль базарындагы вазгыятьне белеште

> 5

ЯРАМЫЙГА КАРАМЫЙ

Балаларны сүгенүдән ничек туктатырга?

> 16

ЯЗУЧЫ ЯЗМЫШЫ

Мәхмүт Галәүнең оныгы Анастасия белән тарихтагы ак таплар хакында сөйләштек

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 166 (28939) | Җомга | 11 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

ЮЛ ҺӘМ ГОМЕР

РӨСТӘМ ГАРИПОВ – ХӘРӘКӘТ ИМИНЛЕГЕ ТУРЫНДА

Безнең халык кызылга туктап, яшелгә генә йөри беләме? Бу сорауны Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы Дәүләт автоинспекциясе идарәсе башлыгы Рөстәм Гариповка бирдек. Аның белән тизлекне киметү хикмәте, аны арттыру куркынычы, йөртүчеләр тәртибе, җәяүлеләрнең җавапсызлыгы, камералар һәм үзе турында сөйләштек.

> 6

Ишетми калмагыз

Казанда халык саны 2050 елга 2 миллионга җитәргә мөмкин. Шәһәр мэры Илсур Метшин шулай дип фаразлый. Исегезгә төшерәбез: 2020 елгы Бөтенроссия халык санын алу мәгълүматларына караганда, Казанда барлыгы 1308660 кеше яши. Шуның 592360ы – ир-атлар һәм 716300е – хатын-кызлар. Күбесе Совет районында: 336927 кеше. Вахитов районында яшәүчеләр иң аз санда: 85005 кеше. Татарстанда яшәүчеләрнең (4004809 кеше – соңгы дистә ел эчендә 218,3 мең кешегә арткан) өчтән бер өлеше Казанга туры килә.

Россия Хөкүмәте 8 яшьтән 17 яшькә кадәрге балаларга айлык түләүләр өчен төбәкләргә өстәмә 27,5 миллиард сум юллый. Бу түләүләр быел апрель аеннан бирле аз керемле гаиләләргә бирелә. Илдә мондый балалар саны – 5 миллион чамасы. Быел әлеге максатка барлыгы 505 миллиард сум тотылачак.
Киләсе елның 1 гыйнварыннан туганнан алып 17 яшькә кадәрге балаларга бердәм универсаль пособие түләнә башлый. Ил башлыгы басым ясап әйткәнчә, аны рәсмиләштерү бик аңлаешлы, гади һәм уңайлы булырга тиеш. Түләү алу өчен Дәүләт хезмәтләре порталы аша, Күпфункцияле үзәккә яки Пенсия фондына барып, гариза тапшырырга мөмкин.

Мобилизацияләнүчеләр өчен матди ярдәмгә салым салынмаячак. Дәүләт Думасы Россия Салым кодексына төзәтмәләрне икенче һәм өченче укылышта кабул иткән. Шулай итеп, контракт буенча кораллы көчләрдә яки Росгвардиядә хезмәт итүчеләр, шулай ук аларның гаилә әгъзалары махсус хәрби операциядә катнашуга бәйле керемгә салымнан азат ителә.
Моннан тыш «тыныч» хезмәткәрләрнең хәрабәләрне торгызу өчен яңа төбәкләргә җибәрелүенә бәйле чыгымнарын каплау өчен түләүләргә салым салынмаячак. Шулай ук хәрби хезмәткәрнең һәлак булуы яки I группа инвалид калуы очрагында кредитын түләүнең туктатылуы сәбәпле алынган керемнәр салымнан азат ителә. Инде килеп, яңа территорияләргә командировкага җибәрелүчеләргә түләнә торган тәүлеклек акчадан салым алынмаячак.

Татарстанда аномаль җылыдан соң кинәт суыту көтелә. Шимбә һәм якшәмбе – 12–13 ноябрьдә – җылы һава саклана: һава температурасы +3...+8 градуска кадәр күтәреләчәк. Температура нормадан 6–7 градуска югарырак булачак. Әмма Татарстан Гидрометеоүзәге яңа рекордлар фаразламый. 1927 елда Казанда ноябрьнең шушы көннәрендә +10...+15 градус теркәлгән. Гидрометеоүзәкнең башлангыч фаразына караганда, киләсе атна башында республикага суык һава үтеп керәчәк. Карлы яңгыр, көчле җил көтелә. Дүшәмбе – 14 ноябрьдә – Татарстанда +2дән –3 градуска кадәр суыта. Сишәмбе – 15 ноябрьдә – температура –2...–7 градуска кадәр төшәчәк. Юлларда бозлавык булырга мөмкин. Сүз уңаеннан, 9 ноябрьдә +1...+5 градус булган. Тәүлеклек уртача температура нормадан 5 градуска арткан.

Районнарда ни хәлләр?

Әлки

Базарлы Матак авыл җирлеге советы урам исемен алмаштыру турында карар кабул итте. Нәтиҗәдә, Полевая урамына Раил Габдрахманов исеме биреләчәк. Белгәнебезчә, Раил Наил улы – танк ротасы командиры, капитан. Украинага махсус хәрби операциягә билгеле бер бурычларны үтәргә җибәрелә. Анда кылган батырлыклары өчен аңа Россия Герое исеме бирелде.
(«Әлки хәбәрләре»)

Мөслим

Рус Шуганы авылында үзара салым хисабына күпер ремонтланды. Бу эш өчен 1 миллион сумнан артык акча тотылды. Рус Шуганы, Татар Смыловкасы, Рус Смыловкасы, Островка авылларын берләштергән Шуган авыл җирлегенең үзенчәлеге: өч авыл Ык елгасының – бер ягында, Рус Шуганы икенче ягына урнашкан. Рус Шуганыннан Татар Смыловкасы авылына Мөслим аша барганда 48 чакрым юл узарга кирәк, күпер аша – 6 гына. Күпер моннан 7 ел элек яраксызга әйләнгән. Зур чыгымнар таләп иткәнлектән, бу чара кичектерелә килгән. Җыенда авыл халкы бертавыштан җирлеккә караган авылларны тоташтыручы күперне ремонтлауны сораган. Шуган авыл җирлегеннән җыелган үзара салымны республика ярдәме белән дүрт тапкыр арттыргач, ике миллион сумга якын акча тупланган.
(Мөслим районының рәсми сайты)

Мамадыш

10 ноябрьдә Мамадышта «Заманча мәктәп» илкүләм проекты кысасында төзелгән һәм «Үсеш ноктасы» федераль үзәкләренең берсе булган табигый-фәнни профильле мәгариф үзәге ачылды. Ул шәһәрнең 1 нче номерлы мәктәбендә эшләячәк. «Үсеш ноктасы» үзәкләре Россия Мәгариф министрлыгы ярдәмендә төзелә. Монда балалар яңа иркен уку бүлмәләрендә химия, физика, биология кебек фәннәрне үзләштерәчәк. Уку бүлмәләре заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән, ә бу исә табигый юнәлешкә карый торган фәннәрне үзләштерүне тагын да мавыктыргыч һәм кызыклы итәргә мөмкинлек бирәчәк.
(«Нократ»)

Ютазы

Районда күчмә «Мобиль поликлиника» комплексы эшли башлады. Ул иң кирәкле диагностика җайланмалары белән җиһазландырылган. Монда районның барлык торак пунктларында яшәүчеләрне кабул итәчәкләр. Алдан төзелгән график буенча Урыссу үзәк хастаханәсенең онкологы, уролог, эндокринолог, ревматолог, лор табибы, невролог, хирург тиешле ярдәм күрсәтәчәк. Моннан тыш, лаборатория, ЭКГ аппараты һәм хатын-кызлар өчен кабинет эшләячәк. Авыл халкына нинди белгечләрнең кайсы көнне эшләячәген фельдшерлар хәбәр итәчәк. Күчмә медицина комплексы табиб амбулаторияләре, шулай ук фельдшер-акушерлык пунктлары территорияләрендә урнашачак.
(Ютазы районының рәсми сайты)

ИМИНЛЕК САКЧЫЛАРЫ

Батырлык, фидакарьлек, теләсә кайсы мизгелдә ярдәмгә килергә әзер булу. Президент Рөстәм Миңнеханов, эчке эшләр органнары хезмәткәрләрен һөнәри бәйрәмнәре белән котлаганда, нәкъ шул сыйфатларны искә алды. Башта ул полициянең участок хезмәткәрләренә машина ачкычлары тапшырды. Аннары министрлык бинасында узган тантанада иң яхшы хокук сакчыларын бүләкләде.

Бәйрәм уңаеннан полициянең участок хезмәткәрләренә ВАЗ-21214 «Нива» машиналары ачкычлары тапшырдылар. «Республика халкы, шәхсән үз исемемнән һәркайсыгызга хезмәтегез, республикада иминлекне тәэмин итүгә керткән өлешегез өчен рәхмәт белдерәм», – диде Рөстәм Миңнеханов тантанада. Аның сүзләренә караганда, Татарстан – сәнәгать ягыннан алга киткән төбәкләрнең берсе һәм монда хокук сакчыларының да өлеше бар. Иминлек юк икән, инвестицияләр дә, туристлар да булмый. «Эчке эшләр органнары хезмәткәрләренең эше һәрвакыт төгәл һәм тотрыклы», – диде Президент. Участок хезмәткәрләрен исә ул хакимиятнең халыкка иң якын вәкилләре дип атады.

Машиналар «2014–2025 елларда Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм җинаятьчелеккә каршы көрәш» программасы кысасында тапшырылды. Министрлык вәкилләре, эчке эшләр органнарына даими ярдәм күрсәтүе өчен, Татарстан Президентына һәм Хөкүмәткә рәхмәт әйтте. Республикада муниципаль хезмәткәрләр системасы эшли, авыл җирендә полиция вәкилләре өчен махсус комплекслар төзелә, министрлык биналары яңартыла һәм башка эшләр башкарыла.

Эчке эшләр министрлыгы – һәрвакыт Россия хокук саклау системасының төп буыны, ә хезмәткәрләр дәүләтнең таянычы булды. Бу хакта Рөстәм Миңнеханов Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгында узган тантанада әйтте. «Сезнең авыр, әмма бик кирәкле һөнәрегез батырлык, фидакарьлек, теләсә кайсы мизгелдә ярдәмгә килергә әзер булу кебек сыйфатларны таләп итә», – диде ул котлау сүзендә. Узган ел нәтиҗәләре буенча Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы Россиядә иң яхшысы дип табылган. Президент фикеренчә, хезмәткәрләрнең һөнәри осталыгы ведомствога иминлек тәэмин итү, хокук бозуларны булдырмый калу, җинаятьләрне ачу өчен нәтиҗәле эшләргә мөмкинлек бирә.

Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, бүген эчке эшләр органнары алдында җитди бурычлар тора. Махсус хәрби операция үткәрү шартларында иң мөһиме – җәмәгать тәртибен һәм иминлеген саклау. Президент экстремизм мәсьәләсенә, бигрәк тә яшьләрне саклауга, профилактика эшенә, юл иминлегенә аерым игътибар бирергә кирәклеген әйтте. Башкарылган эшнең төп нәтиҗәсе – халык ышанычы. «Нык сәламәтлек, тыныч күк йөзе, туганнарыгыз һәм якыннарыгыздан ярдәм телим. Үзегезне саклагыз һәм сезне өегездә һәрвакыт якыннарыгыз көткәнен онытмагыз», – диде Президент.

ХӘВЕФ-ХӘТӘРСЕЗ БУЛСЫН!

ТАТАРСТАНДА «ИДЕЛ» М7 АВТОМОБИЛЬ ЮЛЫНЫҢ 17 ЧАКРЫМЛЫ УЧАСТОГЫ АЧЫЛДЫ

Республикада реконструкциядән соң «Идел» М7 автомобиль юлының 735–753 чакрымнары участогы ачылды. Мондый озынлыктагы юлны республикада беренче тапкыр төзекләндерделәр.

tatarstan.ru

– Бу трасса бик тыгыз иде. 18 километрга якын юл төзекләндерелде. Ул барлык заманча таләпләргә җавап бирә. Ил Президенты, Хөкүмәтенә бөтен ил, шул исәптән безнең республикада төзелгән юллар өчен рәхмәт! Әлбәттә, безнең юл төзүчеләребезгә дә рәхмәт! Республикада әлеге бурычларны хәл итү өчен юл төзелеше ресурслары җитәрлек булуга чын күңелдән шатбыз, – диде Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов.

Президент ассызыклаганча, Татарстанда моңарчы бу кадәр күләмдә эш башкарылганы булмаган. М7 реконструкциясеннән тыш, республикада М12 «Шәле – Баулы» трассасы төзелүен дә искәртте ул.

Чарада катнашучыларны Мәскәүдән видеоэлемтә аша «Росавтодор» җитәкчесе урынбасары Андрей Самарьянов сәламләде. Аның сүзләренә караганда, реконструкция турында карар кабул итү юл-транспорт һәлакәтләре саны арткан чорга туры килгән. «Бүген бу карар тагын да тирәнрәк мәгънәгә ия, чөнки М7 трассасы Татарстан чикләрендә үсә баручы, Санкт-Петербургтан Владивостокка кадәр сузылган «Көнбатыш – Көнчыгыш» коридорына керәчәк», – диде Андрей Самарьянов.

Чувашия чигеннән алып Яшел Үзән районының Исаково авылына кадәр юл участокларында төзекләндерү эшләре 2019 елда ук башланган иде. Участокның гомуми озынлыгы – 17 километр. Нәтиҗәдә юлда хәрәкәт итү полосалары саны икедән дүрткә кадәр арттырылган, 20 сантиметр калынлыктагы асфальт-бетонның өч катламы җәелгән. Моннан тыш, төзекләндерү эшләре барышында 6 яңа юл үткәргеч төзелгән.

Юл хәрәкәте иминлеге турында да кайгыртканнар. 30 километрга якын озынлыкта – яктырту объектлары, 37,5 километр – киртә-коймалар, 400ләп юл билгеләре урнаштырганнар. Автопавильоннар, 13 транспорт тукталышы, җәяүле сукмаклары төзелгән. Тимер юл разъезды бистәсе янында тавыштан саклау экраннары куйганнар. Автомобиль юлы участогын реконструкцияләүгә 5,2 млрд сум акча тотылган.

2024 елга М7 трассасы тулысынча дүрт полосалы булачак. Бу хакта журналистларга «Волго-Вятскупрадор» башлыгы Илдар Минһаҗев хәбәр итте.

– Тагын якынча 110 километр чамасы эшлисе калды. Бу – Башкортстан чигенә кадәрге участок. Бүген кулланылышка кергән 17 километрлы юл республика өчен бик әһәмиятле. Ул Татарстан, Чувашия, Башкортстан һәм Удмуртияне тоташтыра. Бу юлда хәрәкәт бик көчле һәм киеренке иде. Хәзер юлның үткәрүчәнлек мөмкинлеге ике тапкыр артты: тәүлегенә 40000 машинага кадәр йөри ала. Моннан соң хәрәкәт куркынычсыз һәм уңайлы булачак, – диде Илдар Минһаҗев.

Быел автомобиль юлларын ике полосадан дүрткә кадәр киңәйтү эшләре шулай ук Актаныш районында М7 трассасының алты километрлы (1155–1161 км) участогында тәгәлләнгән. Ул «Казан – Екатеринбург» тиз йөрешле транспорт маршруты составына керә. Хәзер М7 трассасының дүрт полосалы участогының озынлыгы 308 км тәшкил итә.

Ләйсән САФИНА

ЧҮП КЕНӘ ТҮГЕЛ

Чүп өчен җаваплы кешеләрне билгеләргә, контейнерлар мәйданын карап-чистартып торырга, сыек калдыклар белән эшләү тәртибен җайга салырга – шушы һәм башка мәсьәләләр үз чиратын көтә. Дәүләт Советы Россия Дәүләт Думасына «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» федераль закон проекты кертергә әзерләнә.

Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты белән Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты утырышында әлеге тема буенча фикер алыштылар.

Сөйләшүдә Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мөхәммәтшин да катнашты.

– Илдә әлегә кадәр каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм юк итү буенча системалы эш җайга салынмаган, – диде ул. – Шулай ук сыек калдыклар, казылган чокырларны чистарту буенча да сораулар күп керә. Халыкны елгаларга төрле калдыклар агызу, Иделнең яшелләнүе дә борчый. Бу Татарстанга гына кагылмый, башка төбәкләрдә дә шулай. Шуңа күрә моны федераль дәрәҗәдә хәл итү кирәк.

Парламент башлыгы билгеләп узганча, федераль законга тәкъдим ителгән үзгәрешләр халыкның чыгымнары һәм тарифлар артуны күз алдында тотмый.

– Төп максат – бердәм механизмны җайга салу, аны эшләтү, аңлаешлы һәм ачык итү. Әлеге закон проектын төбәк операторлары да, бизнес вәкилләре дә, башка төбәкләрдәге коллегалар да көтә. Халыкка да, бизнеска да авырлык килмәячәк, киресенчә, эш тәртибе җайга салынгач, эшләү җиңел һәм аңлаешлырак булачак, – дип ышандырды Фәрит Мөхәммәтшин.

Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе Азат Хамаев фикеренчә, дөрт ел эчендә эшләп килүче яңа система яхшы нәтиҗәләргә иреште. Шул ук вакытта ул яңалык таләп итә, шул исәптән закон ягыннан да.

Билгеле булганча, ике ел элек бу мәсьәләдәге нечкәлекләрне өйрәнү өчен, Дәүләт Советы Рәисе күрсәтмәсе белән ведомствоара эшче төркем төзелгән иде. Шул вакыт эчендә фикер алышулар, башка төбәкләргә чыгып, аларның тәҗрибәсен, килеп туган мәсьәләләрне өйрәнүләр шактый булды. Аларның барысы да шушы закон проектында исәпкә алынган.

Закон проекты буенча төп доклад белән чыгыш ясаган Дәүләт Советының Торак сәясәте һәм инфраструктура үсеше комитеты рәисе Александр Тыгин фикеренчә, иң мөһим мәсьәләләрнең берсе – калдыкларның хуҗасын билгеләү.

– Каты көнкүреш калдыкларының хуҗасы итеп төбәк операторын билгеләргә кирәк. Алар контейнерлар тора торган мәйданны да карап торырлар иде. Хуҗасы билгеле булса, кемнең милкен эшкәртүгебезне, икенче чимал буларак нәрсә алып булуын, аның өчен кем акча чыгарырга, ә кем керем алырга тиеш булуын да аңлар идек. Барысы да үз урынына утырыр иде, – диде комитет рәисе.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Закон проекты төзелеш калдыклары, контейнерлар тора торган мәйданнарны карап тоту, тарифларны җайлау һәм башка мәсьәләләргә кагылышлы федераль закон статьяларына да үзгәреш кертүне күздә тота. Александр Тыгин әйтүенчә, тиешле булмаган урыннарда барлыкка килгән чүплекләрнең 80 проценты төзелеш һәм ремонттан соң калган чүп-чардан тора. Ә әлеге вакытта законда мондый калдыклар белән эш итү тәртибе билгеләнмәгән. Шул уңайдан депутатлар, «төзелеш һәм ремонт калдыклары» дигән терминны кертеп, алар белән эшләү тәртибен төбәкләргә хәл итүне йөкләргә тәкъдим итә.

Ике комитет утырышында тарифлар темасы да әледән-әле калкып чыкты. Депутатлар фикеренчә, ул ачык һәм халык өчен аңлаешлы булырга тиеш. Мәсәлән, «Гринта» җәмгыяте директоры Светлана Ярлыченко әйтүенчә, чүп өчен контейнерлар мәйданына бер җаваплы кешене билгеләргә һәм моны тарифта исәпкә алырга кирәк.

– Без авылларда чүпне атнага ике тапкыр капчык белән дә җыябыз. Ә СанПиН кагыйдәләре буенча алар көн саен җыелырга тиеш. Бу нормалар шулай ук тарифта исәпкә алынсын иде, – диде ул.

Шулай ук депутатлар Дәүләт Думасы Рәисе Вячеслав Володинга һәм Россия Хөкүмәте Рәисе Михаил Мишустинга сыек көнкүреш калдыклары белән эш итүне хокукый җайга салу тәкъдиме белән чыкмакчы була. Россиядә торак фондының нибары 65 проценты гына үзәкләштерелгән канализация белән җиһазландырылган. Авылларда әлеге күрсәткеч гомумән 18 процент кына. Татарстанда исә Россиядәге уртача күрсәткечләрдән бераз гына зуррак. «Әлеге вакытта үзәкләштерелгән су чыгу системасы булмаган йортларда, шул исәптән күпкатлы фатирларда сыек көнкүреш калдыклары белән эшләү тәртибе законда күрсәтелмәгән: «сыек көнкүреш (коммуналь) калдыклар» турында аңлатма, мондый калдыклар туплану буенча эшләнгән һәм расланган методикалар юк», – диелә әлеге мөрәҗәгатьтә.

Зөһрә САДЫЙКОВА

БЕРДӘМЛЕК КӨЧЕ

КАЗАН ХАЛКЫ БЕРНИЧӘ КӨНДӘ 100 ТОННА ГУМАНИТАР ЯРДӘМ ҖЫЙГАН

Битараф калмаганнар. Казаннан Луганск Халык Республикасындагы Лисичанск шәһәренә 100 тонна гуманитар ярдәм озатылачак. Башкалада яшәүчеләр һәм бизнес вәкилләре аны ун көн эчендә җыйган. Волонтерлар исә туплау-әзерләү эшләрен башкарган. Казан мэры Илсур Метшин үзе дә эш барышы белән танышып кайтты.

Биш йөк машинасына төялгән әйберләрне башкаладан кичә озаттылар. Кирәк-яракларны «Игелекле Казан» фондының складына җыйганнар. Гуманитар ярдәм кысасында көнкүреш кирәк-яраклары да, төзелеш материаллары да тупланган. Акча теләнә күчерсәк, ярдәм күләме 20 млн сумны тәшкил итә.

– Безнең халыкның мондый мөнәсәбәте шаккатыра, – дип, сокланууын белдерде Илсур Метшин.

Моннан тыш, Казан халкы, Лисичанскида яшәүчеләргә теләкләр язып, хат та юллаган. Моңа өстәп, Казан укучылары да 200ләп хат әзерләгән. Гуманитар ярдәм белән бергә аларны да җибәрделәр.

Әйтергә кирәк, бу склад ярдәмне җыю һәм туплауның бердәм ноктасына әверелде. Аны тулаүсез нигездә шәһәрнең бер эшкуары тәкъдим иткән. Гомумән, шәһәр буенча барлыгы 18 гуманитар ярдәм җыю пункты ачылган иде.

– 300ләп кешене һәм 90 бизнес вәкилен 18 гуманитар ярдәм җыю пунктында кабул иттек. Монда шәхси эшкуарлар да, зур бизнес вәкилләре дә үз өлешен кертте, – диде шәһәр башлыгы.

Илсур Метшин искәрткәнчә, Яңа елга кадәр ярдәм төялгән тагын өч йөк машинасын Лисичанскига җибәрү күздә тотыла.

Сүз уңаеннан, җыю пунктларында һәм төп складта көн саен утызар волонтер эшли. Шәһәр халкы анда азык-төлек, кием-салым, көнкүреш кирәк-яраклары, җылы юрганнар алып килә. Балалар өчен әйбер җыю да оештырылды.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Газпром төбәкарагаз Казан» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: газ сату идарәсе башлыгы **Азанчеева** Надежда Натановна, бухгалтерлык һәм салым исәбе идарәсе башлыгы урынбасары – бухгалтерлык исәбе һәм хисабы бүлеге башлыгы **Краснова** Юлия Германовна Татарстан Республикасының **«Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «КРС-Сервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте ӘлмәтРемСервис предприятиесенең күтәргеч җайланма машинисты **Бәдретдинов** Илһам Минзөфәр улы, «Татойлгаз» акционерлык җәмгыяте генераль директорының беренче урынбасары – баш инженеры **Гыйматдинов** Айрат Әнәс улы, «Охтин-Ойл» ябык акционерлык җәмгыяте баш инженеры урынбасары **Назаров** Максим Валерьевич **«Өч миллиард тонна Татарстан нефтен чыгару уңаеннан» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы Идарәсенең тикшерү идарәсе башлыгы урынбасары – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Чаллы шәһәре буенча идарәсе тикшерү идарәсе (оешкан җинаятьчел эшчәнлекне тикшерү часте (идарә хокукында) оешкан җинаятьчел эшчәнлекне тикшерү часте башлыгы, юстиция подполковнигы **Әгъләмов** Ленар Рәис улына, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы җинаятьчеләрне эзләү идарәсенең Зеленодольск, Буа, Югары Ослан һәм Тәтеш районнарына оператив хезмәт күрсәтү буенча гомумҗинаятьчел юнәлештәге оешкан җинаятьчелеккә каршы көрәшү бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы **Дорофеев** Евгений Владимировичка, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының җинаятьчеләрне эзләү идарәсе эчке эшләр органнарының җинаятьче затларны эзләү эшчәнлеген координацияләү бүлеге башлыгы, полиция подполковнигы **Королев** Сергей Николаевичка, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе оператив штабы аппараты җитәкчесе урынбасары (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы кадрлары составында калдырылып, Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенә вакытлыча беркетелгән), полиция полковнигы **Сафин** Радик Мәсгут улына, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгы бүлеге башлыгы урынбасары – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Кукмара районы буенча бүлеге төркеме (шәхси состав белән эшләү төркеме) җитәкчесе, полиция подполковнигы **Федоров** Валерий Ивановичка **«Татарстан Республикасы буенча атказанган эчке эшләр органнары хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Казан авыл хуҗалыгы машиналары төзелеше» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Мифтахов** Рафис Зөфәр улына **«Татарстан Республикасының атказанган машина төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Газпром төбәкарагаз Казан» акционерлык җәмгыяте хезмәткәрләре: транспорт бүлеге автомобиль йөртүчесе **Галәтдинов** Ринат Шәйхетдин улына, транспорт бүлеге башлыгы **Ситдыйков** Илмас Әсхәт улына **«Татарстан Республикасының атказанган транспорт хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Татарстан Республикасы Югары Суды судьясы **Абдрахманова** Луиза Әнвәр кызына, Татарстан Республикасы Алабуга шәһәр суды рәисе **Низамова** Жанна Мәсгут кызына, «Татарстан Республикасы Адвокатлар коллегиясе» дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмасының Казан шәһәре Мәскәү районы буенча филиалы мөдире, «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Тимаев** Марсель Фатыйх улына, «Газпром төбәкарагаз Казан» акционерлык җәмгыятенең юридик идарәсе башлыгы урынбасары – шикаять-дәгъваларны карап тикшерү эше бүлеге башлыгы **Саженкова** Людмила Борисовнага, «Газпром төбәкарагаз Казан» акционерлык җәмгыяте генераль директорының хакимият органнары һәм социаль әһәмияткә ия кулланучылар белән эшләү буенча урынбасары **Таһиров** Айдар Энгель улына, «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү мәгариф учреждениесе юридик факультетының эшкуарлык һәм энергетика хокукы кафедрасы доценты, «Россия юристлары ассоциациясе» гомумроссия иҗтимагый оешмасының Татарстан төбәк бүлекчәсе әгъзасы **Селецкая** Стелла Борисовнага, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының юридик бүлеге башлыгы урынбасары **Яруллина** Эльмира Равил кызына **«Татарстан Республикасының атказанган юристы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Әйтеп кенә бактым

Шулай яшәп ятабыз

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Соңгы вакытларда саплам-саплам гына йоклыйм. Ничәдә ятсам да, төнге икеләрдә йокы миннән кача башлый. Әйләнгәләп-тулгангалап ятам да, аптырагач, торып утырам. Кухня ягына чыгып, кәгазьгә язгалаган-сызгалаган булам. Тик башыма бер җүнле уй да керми.

«Олыгайган саен йокылар сак,

Үткәннәргә хәтер еш кайта», – дип җыр көйләгән булам. Җырның көен кем язганын онытдым инде, сүзләре Равил Фәйзуллинныкы икәнне хәтерлим. Без аны бераз үзгәртеп: «Зур юлларга чакырып, ил дәшә», – дип тә җырлый идек. Бу яшьтә ил чакырган зур юлларга чыгып булмый шул инде. Бүген бөтен эш – хәтердә казынып яту.

Студент чакта Камал театры спектакльләрендә «массовка»ларда катнаша идек. Николай Погодин пьесасы буенча куелган «Баһадирлар» спектаклендәге Ленин образы истә калган. Юлбашчы рolendә – СССРның халык артисты Шәүкәт абый Биктимеров. Ул сәхнәгә чыгуга, тамашачы аягүрә басып кул чаба башлый иде. Ленинның ялкынлы чыгышындагы: «Безнең юл бер генә. Ул үлемсез!» – дигән сүзләр аеруча истә калган. Алар, бәлки, онытылыр да иде, әмма тормыш Ленин бабай сызган юлдан гына бармый башлый да, киләчәккә юл бер генә түгел, ахрысы, юлбашчы ялгышкан, дип уйлап куясың. Уйлый торгач, үземне тынычландырган булам, Аллаһы Тәгалә бер һәм бердәнбер булса да, аңа һәркем үз юлы белән бара бит, дим. Һәрхәлдә, дин әһелләре шулай сөйли.

Хәер, безнең үз юлыбыз бар: үткәнебезне ватып-җимереп, алга йөгерәбез, тормыш яхшыланган кебек була. Әмма бераздан ниндидер хаталар җибәргәнебез башка суга да, кире үткәнгә кайткалыйбыз. Бүгенге тормыштан да СССР заманы исе килеп киткәндәй була. Белоруссия Президенты Александр Лукашенко, халыкны Октябрь революциясенең 105 еллыгы белән котлап, «социалистик республикалар союзының «совет проекты» үзара тату яшәргә омтылган илләр өчен маяк була ала» дигән фикер дә әйтеп куйды хәтта. Кайбер мәгълүматларга караганда, бүген россиялеләрнең 58 проценты СССРга кире кайтуны хуплый икән. Алар – нигездә, авыр тормышта яшәүчеләр, дип тә өстәп куйганнар. Илдә ярлы-ябагайлар нужәли шул хәтле күп инде? Каршылар халыкның 31 процентын тәшкил итә. Шул ук вакытта хуплаучыларның шактые инде үткәнгә кайту мөмкин түгел дип саный. Хәзерге яшь буынны патриотик рухта тәрбияләүдә совет чорындагы кайбер алымнарны кулланабыз үзе, мәсәлән, ГТО нормалары кереп килә. Ә менә әлеге дә баягы Лукашенко совет чорының иң зур казанышларын саклап кала алганга горурлана. Үткәнгә кайту кичәгене сүзгә-сүз кабатлау түгел инде ул. Озын-озак сәфәргә чыкканда, кеше юлга иң кирәкле, иң файдалы әйберләрне генә ала. Җәмгыять тә кешеләрдән тора һәм үсеш юлында файдасыз йөкне үзе белән алмаячак. Ә менә башта барын да нигезенә хәтле җимереп, ил-йортны буш җирдә яңадан төзи башлау – бик авыр, четерекле эш.

Безнең ил гомер-гомергә юлның әнә шул иң авырын сайлап яши кебек. Безгә тыныч кына гомер итәргә язмаган, ахрысы.

Боларны нәрсәгә язам инде? Кемгә кирәк акыл сату? Бераз күңелне бушатып, кешечә йоклап булмасмы дип хыяллану гына инде бу. Шушы урында язмамны тәмамларга уйлаган идем, телевизор экранына күз төште. Россиянең атказанган артисты, Ленин комсомолы премиясе лауреаты Борис Галкин белән әңгәмә күрсәтәләр. Актер туган илне, аеруча илнең тарихын яратуы турында хисләнеп сөйли. Борис Галкинның киногеройлары да – нигездә, хәрбиләр. Бу Россия тарихының башлыча сугышлардан торуына бәйле түгел микән, дип уйлап куйдым.

КЕМНӘР СЕЗ, ЛИДЕРЛАР?

Ул көнне – 1982 елның 11 ноябрендә – без, пединститут студентлары, Казан читендәге яшелчә базасында мичкәләргә тозлау өчен кәбестә тутыра идек. Эш антисанитария шартларында бара, әмма бу безне бер дә борчымый, чөнки беләбез: беребез дә кибеттән тозлы кәбестә алмаячак.

Үтмәс товарларны ул елларда үтемлерәк икенче товарларга кушып саталар иде. Кибетләрдә ит һәм май (атланмай) арзан, әмма талонга бирәләр. Казан пропискасы булып, талонга ия булсаң да, аларны алу өчен бик озак чират торасы. Әмма бу безне кайгыга салмый. Күбебез авыл балалары буларак, бәрәңге белән итне өйдән алып киләбез, суыткычлар булмаганлыктан, кышкы суыкларда ит тәрәзәдән тышкы якта эленеп саклана. Хәер, авылда да иткә муллык бик ташып тормый, җәй көннәрендә сөтле аш ашау традициясе киң таралган. Кыскасы, совет чоры диетасына күнеккәнлектән, без юклыкны бер дә тоймый идек.

КПСС Үзәк Комитеты Генераль секретаре Леонид Ильич Брежневның үлемен иртән радиодан хәбәр иткән булганнар, әмма ваемсыз студент радио тыңлап утырамы соң инде?! Аның лекциягә (бу очракта яшелчә базасына) ашыгасы бар. Кайгылы хәбәрне Левченко бистәсендәге яшелчә базасына якын урнашкан фатирда яшәүче бер төркемдәшебез генә – соңыннан Сарман районы газетасында журналист булып гомерен уздырачак Зөлфия Хәмзина гына ишеткән икән. Эш барышында, ваемсыз гына итеп: «Иптәшләр, ишеттегезме, Брежнев үлгән», – диде. «Юк сүз сөйләшмә, алып китәрләр үзеңне», – дигән авазлар ишетелде, хәбәрне беребез дә чынга алмады.

1976 елда кичерелгән инсульттан соң бик авыр сөйләшә башлаган совет лидерының культы шундый итеп тудырылган иде: совет кешесенә ул үлемсез булып тоела. Пиджагына чамасыз күп орден-медальләр тагарга һәвәслеге, авызын көчкә ачып сөйләшсә дә, озын-озын докладлар укырга мәҗбүр ителүе белән лидер үзе турында бихисап анекдотлар тууга сәбәп булса да, илдә бернинди дә канәгатьсезлек сизелми, башка төрле тормыш һәм башка җитәкче була ала дип башка да китермибез. Бернинди дә протест юк, без, мәктәптә «Кече җир», «Чирәм җир» китапларын конспектлаштырып тәрбияләнгән буын, диссидентлыктан бик ерак идек.

Шулай да Брежнев үлеме аңнарда борылыш китереп чыгарды. Генсекны алыштырган икенче лидер – шулай ук картаеп баручы һәм авыру Андропов әмере белән көпә-көндез урамнардан, гастрономнардан, сауналардан эш вакытында кәеф-сафа корып йөргән халыкны чүпләп җыеп ала башлагач, бигрәк тә мәгълүмат кырына зур җитәкчеләрнең эш эшлисе урынга, мунча кереп, сыра эчеп ятулары хакында рәсми хәбәрләр чыгарылгач, ваемсызлык бераз онытыла төште. Болай барып булмый, илдә чынлап та реформалар кирәк икәне аңлаган кешегә аңлаешлы иде. Әмма Андропов игълан иткән «ау» эпопеясы озак бармады, ничек кискен башланса, шундый тизлек белән туктады да.

Андропов чоры миңа башка бер нәрсә белән ныграк тәэсир итте. Китапханәләрдән һәм уку залларыннан купсанлы һәм калын Брежнев томнары чыгарып ташланды. Уку залына лекция белән килгән институт лекторы, доцент ханымның кулында инде Андропов томы иде. Уйландыра иде бу: димәк, лидерның фикерләре үзе исән чакта гына ниндидер кыйммәткә ия, шәхес үлү белән, идеяләре чүпкә ташлана. Томнарның мондый тиз «инфляция»се аңлаган кешегә юлбашчыларны идеаллаштырырга ярамавын искәртә иде. Кеше буларак, аларның да ялгышырга хакы бар. Әмма аларны ирдә вакытта хатадан имин дип игълан итү зур фаҗигаләргә китерә ала. 1970 еллар ахыры – 1980 еллар башында СССРның бик тирән кризиска кереп батуы – шуның нәтиҗәсе. Бер дә кирәкмәгәннән башланган һәм ике системаның каршы торуын кискенләштергән әфган сугышы – шуның җимеше. Ә бит Брежнев идарәсенең беренче чоры җитди генә икътисади реформалар, уңышлы нәтиҗәләр белән тарихка язылды. 1966 – 1970 еллар бишьеллыгы тиктомалдан гына «алтын бишьеллык» дип аталмаган. Ул еллардагы икътисади сикерешкә бөтен беркайчан да ирешелмәде. Аннан башка да уңай үзгәрешләр байтак иде. Авыл кешесе гарантияләнгән хезмәт хакы ала башлады, завод-фабрикаларда уңышлы эшләгән өчен премия дигән матди стимуллар барлыкка килде. Әмма болар барысы да соңыннан юнитык сү белән чыгарылып ташланган кебек онытылды. Игълан ителгән яңа реформалар барысы да юләрләр йортында язылган кебек тәэсир калдыра башлады. Азык-төлек программасы дип, шәһәрдән авылга камыш тәэп кайтулар, интеллигенциянең кулына капчык тоттырып, скверлардан үлән йолкырга мәҗбүр итәргә тырышулар – боларның барысының да ахмаклык икәнен аңлаган хәлдә кешеләрнең шуны көндәм генә «йотуы» – илнең тупикка

vk.com

килеп терәлүен аңлата торган сигналлар иде. Илдә сүз иреге юк, билгеле, әмма кот очарлык репрессия еллары да артта калган иде. Һәрхәлдә лидерлар турында анекдотларны курыкмыйча сөйлибез, үзара сөйләшкәндә җитәкчелекне тәнкыйтьләүдән шүрләми идек. Бүгенге вазгыять башкарак. Кешеләр аз гына «колея»га сыймаган сүз әйтүдән дә курка, бер-берсенә ышанмый башладылар. Җиңелчә генә тәнкыйть тә чамадан тыш кыюлык булып санала.

Брежнев үлеме белән СССРда «купшы җеназалар бишьеллыгы» дип аталган чор башланды. Югарыда зур йөк тартырга сәләтле сау-сәламәт шәхес таба алмый интектеләр. Алмаш әзерләнмәгән, әллә лидерның үлемсезлегенә политбюрода да ышана башлаганнар шунда. Үзәк Комитетка телефон шалтыравы турында анекдот шул чакта тугандыр, мөгаен. «Алло, – ди телефон чыбыгының теге башындагы кеше, – сезгә Генераль секретарь кирәкмиме?» «Сез нәрсә, акылдан яздыгызмы әллә?» – ди Кремль телефоны, нәфрәтләнеп. «Әйе, әйе, – ди вакансия эзләүче тавыш, – шуңа өстәп карт һәм авыру да әле». Ул чактагы лидерларга халык авыз иҗаты шундый үтергеч сарказм белән бәя бирә башлаган икән, бу кимчелекләр аларның типик сыйфатына әверелгән дигән сүз. Күрәсең, системаның үлеме алдыннан аны эшкә яраклы кеше җитәкли алмый торгандыр. Лидерларның үзләрен акылдан язган кебек тотулары, фаҗигагә илтә торган авыр карарларны бик җиңел кабул итүләре тарихи закон булырга тиештер дип уйлыйм.

Хәзерге глобаль капитализмда да күзәтелә бит бу хәл. Дөньяның иң куәтле державасы белән чиктән тыш карт һәм авыру кеше идарә итә. Шуңа тиң анекдотлары да тумый калмый инде, билгеле. Һәлакәткә барган системаның дилбегәсен тотучыларны Байден турындагы менә бу анекдот та ачып сала. «Байден Бөекбритания королевасыннан сорый: «Сез ничек шундый нәтиҗәле хөкүмәт төзи алдыгыз? Киңәш бирә алмассызмы?» «Иң мөһиме тирә-ягыңда акыллы кешеләр булсын», – дип җавап бирә королева. «Минем тирәдә акыллы кешеләр булуын ничек белергә соң?» – дип сорый яңадан Джо. Королева төймәгә баса да Борис Джонсонны чакырта. «Әйт әле миңа, Борис, – ди, – синең әниеңнең баласы бар. Тик ул сиңа абый-эне дә түгел, апа-сеңел дә түгел. Ул кем?» «Ул – мин», – дип тоткарлыксыз җавап бирә Джонсон. Байден Америкага кайта да вице-президент Камала Харриска шул ук сорауны бирә. Харрис җавапны уйлау өчен вакыт сорый. Консультантларга әйтеп карый, берни дә белмиләр. Аптырагач, ире Дугласка бирә табышмакны: «Синең әниеңнең баласы бар. Тик ул сиңа абый-эне дә түгел, апа-сеңел дә түгел. Ул кем?» – ди. «Бик җиңел, – ди Дуглас, – ул – мин». Вице-президент, шатланып, Байден янына килә. «Мин берникадәр тикшеренүләр үткәрдем һәм сорауның җавабын бирә алам. Ул – минем ирем Дуглас Эмхофф», – ди. Байден сикереп тора һәм Харрисны тотып: «Ялгыштың, ул – Джонсон», – дип кычкыра».

Бу анекдот кына, билгеле, әмма АКШ лидерының реаль гамәлләре һәм сөйләгән сүзләре дә шуңа бик якын. Әле яңа гына The Washington Post газетасы лидерның бертуктаусыз сәер һәм дөреслектән ерак торган белдерүләр игълан итеп торуын аңа «Абсолют Пиноккио» дәрәҗәсе биреп билгеләп үтте. Аннан алдарак андый дәрәҗәгә Трамп лаек булган. Болар икесе дә бик карт, беренчесе нык авыру да, сөйләгән сүзләре дә юләрлектән ерак түгел, кыскасы, Генераль секретарь вакансиясенә туры киләләр. Бер Америкада гына шул хәл булса, түзәр дә идең. Дөнья сәясәтендә карт һәм тилемсә лидерларның тулы бер плеядасы дилбегә кага бит.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

Зөһрә
САДЫЙКОВА

ОЗЫН ЮЛ

ТАШЛАМАЛЫ АВТОКРЕДИТНЫҢ ТӨП ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Яңа машиналар сату базарында тынлык. Узган ел белән чагыштырганда, Россиядә аларны сату октябрьдә 62,8 процентка кимегән. Кайбер белгечләрдән, мондый хәлнең булганы юк иде, дигән сүзләр дә ишетергә туры килә. Сәбәбе – машиналарның хаклары өскә сикерү. Анысына исә дефицит гаепле. Аның каравы үзебездә җитештерелгән машиналарга игътибар арткан. Моңа, бердән, дөнья хәлләре этәргеч ясаса, икенчедән, машинаны ташламалы шартларда алырга мөмкинлек бирүче махсус дәүләт программалары ярдәм иткән. Без автомобиль базарындагы вазгыятьне һәм дәүләт программасында катнашу шартларын ачыкладык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Үзеңнеке – үзәктә

Машина базарындагы вазгыятьне аңлар өчен, саннарга күз төшереп карыйк. Европа бизнесы ассоциациясе мәгълүматлары буенча, быелның февралендә 121442 яңа җиңел машина сатылган булса, майда нибары – 24873. Мондый күрсәткечләр хөкүмәтне дә сөендерми, билгеле. Килеп туган вазгыятьне уңай якка борып җибәрү өчен, июньдә автомобиль сәнәгате үсешенә багышланган зур киңәшмә уздыралар. Нәкъ менә шунда Россиядә җитештерелгән машиналарны алырга ярдәм итәчәк дәүләт программаларын тормышка ашыруны эшләтеп җибәрергә кирәк, дигән карар кылына да инде. Күрелгән чаралар үз эшен эшли дә шикелле: майдан соң машина базарында бераз җанлану башлана. Әйтик, июньдә – 27,8 мең, июльдә – 31,4 мең, августта – 41,7 мең, сентябрьдә 47,7 мең машина сатылган. Октябрьдә аеруча АвтоВАЗ популярлык казана. Ай дәвамында компания 19145 автомобиль сата. Икенче урында – Тулада җыела торган Кытай машинасы «Haval Jolion». Шулай да белгечләр, узган ел белән чагыштырганда, сатуның 60,8 процентка кимүен белдерә.

Зөлфәт Галимов кешеләргә машиналар сайлап алырга ярдәм итә. Казанда һәм берничә районда салоннары бар. Машина базарындагы вазгыятьнең февральдән соң үзгәрүен ул да инкарь итми. Шул вакыттан бирле машина сатып алучыларның шактый кимүен әйтте. Узган еллар белән чагыштырганда, аерма зур, ди ул. Тик соңгы ярты елда машина сату дәрәҗәсе бер тирәдә тирбәлүенә дә басым ясады. «Бу айда автомобильләр күбрәк, тегендә азрак сатылды, дип кистереп әйтеп булмый. Бер айда бер салонда азрак булса, икенчесендә артырга мөмкин», – ди ул.

Ә менә чит илдә һәм үзебездә җитештерелгән автомобильләрне сатып алудагы үзгәрешләр күзгә күренеп арткан.

– Узган берничә елда халыкның күпчелеге чит ил машиналарына игътибар бирә иде, чөнки аларның бәяләре ул дәрәҗәдә «тешләмәде». Хәтта 1 млн сумга кадәр яңа чит ил машинасын алырга мөмкин иде. Быелның февраленнән вазгыять кисәк үзгәрде. Ул чорда кайбер төр машиналарны сату бөтенләй тукталып торды. Аннан соң базарга бәяләре 25–30 процентка күтәрелеп чыкты. Марттан соң хаклары якынча 10 процентка төште. Чит ил машиналарының бәяләре «өскә сикергәч», халык үзебезнекеләргә өстенлек бирә башлады. Билгеле, Россиядә җитештерелгән автомобильләргә запас частьлар табу белән дә авырлыклар юк. Карар кабул иткәндә бу да төп факторларның берсе булып тора, – ди белгеч.

Чит ил машиналарын сайлаучылар арасында сирәкләр генә яңаны ала (мәсәлән, бер автосалонда атнага бер-ике машина сатыла). Күпчелек халык кулланышта булган автомобильгә өстенлек бирә икән.

– Бездән еш кына: «Доллар төште бит. Нилектән машина бәяләре шул дәрәҗәдә тора?» – дип сорыйлар. Монда эш долларда түгел, ә чит ил автомобильләренең Россиягә аз һәм урау юллар аша керүендә, – дип аңлата ул.

Зөлфәт Галимов фикеренчә, Россия машиналарына сорау артуның тагын бер сәбәбе – ташламалы шартларда алырга мөмкинлек бирүче махсус дәүләт программалары.

Белгеч сүзләренчә, ул эшли торган автосалонда сатыла торган җиңел машиналарның якынча 80 проценты кредитка алына. Сүз уңаеннан, илкүләм кредит тарихлары бюросы мәгълүматлары буенча, Татарстанда автокредит алу күләме быелның 9 аенда шулай ук 40 процентка төшкән.

– Дәүләт программасын аеруча авылда яшәүчеләр яратып файдалана. Шуңа күрә районда яки зур шәһәрләргә якын булган автосалоннардагы машиналарның күпчелеге әлеге программа кысасында сатыла, ягъни ташламалы кредитлар бирелә. Шәһәрдә исә кулланышта булган автомобильләргә өстенлек бирәләр. Шулай итеп, бер автосалон челтәрендәге машиналарның 40 проценты дәүләт программасы буенча алына, 40ы – кулланышта булган һәм яңа чит ил автомобиле, калган 20 процентын кулдагы акчага алалар. Әлеге вакытта «Лада Гранта», «Лада Веста», «Лада Нива Легенда», «Лада Нива Травел» машиналарына бернинди дә кытлык юк, – диде Зөлфәт Галимов.

Ташламалы автокредит нәрсә ул?

Ташламалы автокредит программасы турында күп сөйләнелә. Аның кысасында нинди машиналар алырга мөмкин соң?

Билгеле булганча, әлеге дәүләт программасы биш ел эшләде. Һәм моңа кадәр үзен шактый уңышлы күрсәтте. Әйтик, 2021 елда аның өчен бүлеп бирелгән акча беренче яртыеллыкта ук бетте. Быелның июнендә программа кабаттан яңартылды.

Аңлатып китик: Россиядә эшләнгән машиналарны кредитка алган вакытта 20 процент ташлама бирелә, ягъни ул кредит процентларын һәм иминиятләштерү өчен кертелгән акчаны каплый. Быел әлеге программаны тормышка ашыру өчен 20,7 млрд сум акча бүлеп бирелгән.

Төп шартларга килгәндә, беренчедән, ташламалы кредит үзебездә җитештерелә торган машиналарга гына бирелә. Аерым алганда, УАЗ, АвтоВАЗ, ГАЗ, УРАЛ, КамАЗ машиналарын 20 процент ташлама белән сатып алырга мөмкин. Шулай да быел Кытай машинасы «Haval Jolion» да программага кертелгән. Тагын бер шарт – автомобиль бәясе 2 млн сумнан артмаска тиеш.

Белгечләр билгеле бер төрдәге машинаны ташламалы кредит белән сатып алганда, күпме акчаны янга калдырып булуын исәпләп чыгарган. Әйтик, «Лада Гранта» бүген 678300 сумнан башлап 755900 сумга кадәр тора. Ә ташламалы кредит белән аны 374810 сумнан алып 429130 сумга кадәр алып булачак. Шулай ук, мәсәлән, «Granta Drive Active» автомобиле ташламалы кредитсыз 809900 сумнан алып 907900 сумга кадәр тора. Ә барлык ташламалар белән аны 466930–535530 сумга алу мөмкинлеге бар. Классик «Нива» белән дә шундый ук хәл. 807–809 мең сум торган машинаны дәүләт программасы кысасында 464830–466230 сумга алырга мөмкин.

Игътибарга алынырга тиешле тагын бер урын бар: быелның 1 июненнән чыгарылган машиналарга ташламалы кредитны программада катнашучы барлык банклар да бирә. Ә менә аңа кадәргеләрне алганда авырлыклар бар икән. Кайбер төр автомобильләрне алганда «Альфа банк» белән эшлисе һәм шартларын аерым карарга туры килүе бар.

Шулай да кризис, илдәге гомуми вазгыять, халыкның кәефе һәм мөмкинлеге барыбер үзенекен итә. Ташламалы кредит ярдәмендә 80 мең машина сатарга уйлаган булсалар да, «Комсомольская правда» китергән мәгълүматлар буенча, октябрь башына программа бюджетының яртысы гына сарыф ителгән. Бу вакытка нибары 22 мең машина сатылган.

ӘЛЕГЕ ВАКЫТТА ТАШЛАМАЛЫ КРЕДИТТАН КЕМНӘР ФАЙДАЛАНА АЛА?

- ✓Бер һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган баласы булган гаиләләр;
- ✓элек машинасы булмаганнар;
- ✓дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдә эшләүчеләр;
- ✓сәламәтлек саклау системасындагы дәүләт оешмаларында эшләүче медицина хезмәткәрләре, ягъни «Работник образования» һәм «Медицинский работник» программаларында катнашучылар;
- ✓Трейд-ин программасы нигезендә машина алучылар: кимендә алты ай элек чыккан һәм 1 елдан артык хуҗасының милке булып саналган иске машинаны тапшырып, яңаны алу.

Шушы көннәрдә Россия Сәнәгать министрлыгы пенсионерларга һәм хәрбиләргә дә ташламалы автокредит программасыннан файдалану мөмкинлеген караячаклары турында хәбәр итте. Ведомство башлыгы Денис Мантуров сүзләре буенча, норматив актлар эшләнеп бетәчәк һәм бу категория гражданнар да программага кертеләчәк.

Программада нинди банклар катнаша? *«ВТБ» һәм «Открытие» банклары. Әлеге банклар барлык автосалоннарда да бар.*

Программада «Лада» автомобиленең нинди маркалары катнаша? *«Granta 22», «Granta Drive Active 22», «Granta Cross 22», «Niva Legend 22» һәм «Niva Travel 22».*

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ АВТОИНСПЕКЦИЯСЕ БАШЛЫГЫ РӨСТӘМ ГАРИПОВ:

«ТИЗЛЕК ЯХШЫГА ИЛТМИ»

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

:: Рөстәм Рамилевич, сезнең бу вазыйфага билгеләнүегезгә инде ярты елга якын вакыт узды. Эше яңа түгел, әмма җаваплылык күпкә зуррак. Үз алдыгызга нинди максатлар куйдыгыз?

– Чыннан да, җаваплылыгы зуррак, юнәлешләре бик күп. Катлаулы эш, әмма авыр дип зарлана алмыйм. Чөнки бу вазыйфада миңа кадәр эшләгән Рифкат Нургали улы Миңнеханов, Ленар Ринат улы Габдрахмановтан калган эш системасы, алар туплаган команда беркая да китмәде. Кирәк чакта киңәшләшә алабыз. Шуңа күрә эштә хәл ителә алмаслык проблемалар килеп чыкмый. Команда бик мөһим. Бүген бу вазыйфага килгәнмен икән, моңа кадәр Чистай, Нурлат, Түбән Камада бергә эшләгән егетләрнең дә өлеше бар. Төп максатыбыз шул ук кала: юл һәлакәтләрен киметү, иминлекне арттыру.

:: Әмма быел юлларда куркыныч аварияләр турында хәбәрләр күбрәк булды. Сәбәбе нәрсәдә?

– Быел Татарстан юлларында аварияләр саны да, анда имгәнүчеләр дә кимеде. Кызганыч, гомере өзелгән кешеләр бишкә күбрәк. Беләсезме, корбаннар турында саннар һәм процентларда сөйләргә тел дә әйләнми. Әмма без статистика турында әйтергә мәҗбүр. Сәбәбенә килгәндә, куркыныч һәлакәтләр күп булды. Әйтик, Казан – Оренбург юлында йөк машинасы белән «Ларгус» бәрелешеп, берьюлы 7 кешенең гомере өзелде.

:: Хәлне үзгәртү өчен, юлларда тизлекне чикләү тәкъдимнәре булды. Әйтик, шәһәрдә сәгатенә 40 чакрымнан арттырмаска. Бу гына ярдәм итәрме?

– Тизлекне чикләү турында Хөкүмәт комиссиясендә дә әйттек. Сөйләшә башлагач, төрле фикерләр булды. Минемчә, тизлекне чикләүнең файдасы булачак. Моңа 100 процентка ышанам. Бөтен җирдә 40 чакрым куеп чыгарга кирәк, димибез бит. Моның кирәге дә юк. Авария килеп чыгу куркынычы булган урыннар турында сүз бара. Мәктәпләр, балалар бакчалары янында куела инде ул. Күреп торабыз бит: юл һәлакәтләренең 90 проценттан артыгы тизлекне арттыру аркасында килеп чыга. Юлдан төшеп китүләрнең дә, каршы якка чыгуларның да сәбәбе әнә шуңа барып тоташа. Рөхсәт ителгән тизлек белән барсалар, фаҗига булмас иде.

:: Безнең халыкны чикләү һәм штрафлар белән генә тәрбияләп була дигән сүзме бу?

– Штраф кына түгел, әлбәттә. Юл иминлеге пропагандасына да зур игътибар бирелә. Бу эш белән бездә аерым бүлек шөгыльләнә. Алар район һәм шәһәрләрдә дә бар. «Юл хәрәкәте иминлеге» дәүләт бюджет учреждениесе дә зур ярдәм күрсәтә.

:: Сез юлларның сыйфатыннан канәгатьме?

– Юллар яхшы булганда, аварияләр күбрәк тә килеп чыга әле. Ә начар юл аркасында булганнары бик аз. Моны статистика да раслый. Андый урыннар ачыклана икән, әлбәттә, чарасын күрәбез. Юлчылар да тиз арада төзәтергә тырыша. Әмма, аңлыйсыздыр, аварияләр азрак булсын, акрынрак йөрсеннәр дип, начар юллар төзи алмыйбыз. Һәлакәтләр килеп чыкмасын дип, кешене машинадан атка утырту да мөмкин түгел. Бөтен җирдә тизлекне дә чикли алмыйбыз. Килешәсездер, яхшы юлда машинада тиз бару барыбызга да ошый. Әмма һәр нәрсәнең тәртибе бар.

:: Татарстанда рөхсәт ителгән тизлекне арттырырга мөмкин булган юллар бармы?

– Сүз, әлбәттә, федераль юллар турында бара. Әмма тизлекне арттырырга ашыкмас идем. Моның өчен юлның яхшы булуы гына җитми. Башка сәбәпләре дә бар. Әйтик, юлга кыргый җәнлекләр килеп чыгарга мөмкин. Тизлекнең 10 чакрымга азрак булуы да зур әһәмияткә ия. Бу – кеше гомере дигән сүз. Бездә бит 110 билгесе торса, халык аны 130 дип кабул итә. Тик бу андый тизлек белән йөрергә ярый дигән сүз түгел. Әйе, штраф салынмый, әмма куркыныч авария булып, җинаять эше кузгатылса, кагыйдә бозу булып санала.

:: Соңгы елларда юлларны моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә күп төзибез. Моның иминлеккә файдасы булачакмы?

– Юл иминлегенә уңай йогынты ясаячак. Чөнки яңа юллар башкаларында хәрәкәтнең кимүенә китерәчәк. Аннары бу юллар торак пунктлар аша да узмый бит. Монысы да – иминлек.

:: Инспекторлар күбрәк вакытта, туктатып, һич югы, киңәш бирә иде. Ә камераларны узасың да китәсең инде. Ничек уйлыйсыз, зур юлларда инспекторларның санын арттыру файдалы булмасмы?

– Без дә аларның санын арттырыр идек. Әлегә исә ничә кеше бар, шулар белән эшлибез. Төп игътибарны авария килеп чыгу куркынычы булган урыннарга бирәбез. Килешәм, инспекторлар басып тормагач, иркенәеп киткән йөртүчеләр дә бар. Камералар үз эшен үти. Әмма әлегә алар исерек килеш рульгә утыручыларны, наркотик кулланучыларны ачыклый алмый.

:: Камералардан тагын ниләр көтәргә?

– Киләчәк – камераларда. Башта алар тизлекне генә төшерсә, хәзер каеш эләктермәгән, рульдә барганда телефоннан сөйләшкән йөртүчеләрне ачыклый. Дөрес борылмаучыларны, автобус полосасына керүчеләрне «күрә». Камералар ачыклый алган кагыйдә бозу төрләре 12гә җитте.

Фото һәм видеотеркәү системалары бездә 2008 елда барлыкка килде. Нәтиҗәдә авария күрсәткечләрен сизелерлек дәрәҗәдә киметү мөмкин булды. Әйтик, 2007 елда Татарстан юлларында 5995 юл һәлакәте теркәлгән, аларда 7723 кеше имгәнгән, 769ы һәлак булган. 2021 елда бу саннар 3967, 4560 һәм 313 булды.

:: Үзегез рульгә утыргач, инспекторларның туктатканы бармы?

– Туктаталар. Күрешәбез, хәлләрен белешәбез дә юлыбызны дәвам итәбез.

:: Ничек уйлыйсыз: юл инспекторы – абруйлы һөнәрме?

– Авыр, әмма абруйлы хезмәт.

:: Сүз уңаеннан, йөртүчеләр авария урынында сезнең хезмәткәрләрне еш кына озак көтәргә туры килүдән зарлана.

– Аварияләрне «европротокол" аша теркәргә киңәш итәм. Бу очракта вакыт әрәм булмый.

:: Үзегез дә рульдә йөрүче кеше булаарак, юлдагы тәртипне ничек бәялисез?

– Миңа калса, безнең йөртүчеләр тәртипле. Күреп торам, бу сүзләрем гаҗәпләндерде сезне. Чынбарлыкта шулай бит. Әле менә бүген Казан үзәген урап кайттык. Юл билгеләре тора, сызыгы сызылган. Һәркем үз юлыннан бара. Миңа калса, кеше юлда тәртипле йөрсен өчен, дәүләт барлык шартларны да булдыра.

:: Йөртүчеләр кагыйдә бозмасын өчен күрелгән чаралар аз түгел. Ә менә җәяүлеләр белән нишләргә? Кайчак алар, гафу итегез, үзләре белә торып, машина астына керә кебек.

– Бу мәсьәләгә аерым игътибар итәсем килә. Җәяүлеләр өчен дә шартлар тудырыла. Әйтик, көнгә ике кеше генә узарга мөмкин, әмма зур суммалар сарыф итеп, дәүләт ул урында җир өсте кичүе төзи. Ә кеше тота да ярамаган урында чыга. Коймa аша сикереп чыгалар бит! Алай ярамаганын ничек җиткерергә? Беренче чиратта, пропаганда, аңлату эшләре алып барырга кирәк. Төнлә чыксаң, яктылык



Шәхескә шәхси сораулар

– Спорт белән шөгыльләнәсезме?
– Кыш җиткәнче велосипедта йөрим.
– Балаларыгызны ничек тәрбиялисез?
– Күптән түгел улым белән булган хәлне сөйлим әле. Аның белән урамнан барабыз. Мин – җәяү, ә ул – самокатта. Юл аркылы чыгу урынына җиткәч, самокатыннан сикереп төште дә, җәяүләп китте. Балалар бакчасында шулай өйрәткәннәр икән. Рәхмәт аларга! Пропаганда мәсьәләсендә Мәгариф министрлыгы да зур эш башкара. Мәктәпләр, бакчалар тырышмаса, мондый нәтиҗәгә ирешеп булмас иде. Ике кызым «Адымнар» гимназиясендә белем ала. Зур кызымның бу инде – бишенче мәктәбе. Шөкер, икесе дә яхшы укыйлар.
– Концерт-театрларга йөрергә вакытыгыз каламы?
– Иптәшем белән ял көннәрендә йөрергә тырышабыз.
– Татарстанның Дәүләт автоинспекциясе җитәкчесенә туганнары, дуслары, танышлары ярдәм сорап еш шалтыратамы?
– Бу вазыйфада шалтыратмыйлар. Беләсезме, без бит әле кагыйдә бозу очракларын ачыклау белән генә шөгыльләнмибез, үз хезмәткәрләребезне дә тикшереп торабыз. Үзем кул астында эшләүчеләрдән мондый хәлләр булмасын дип таләп итәм икән, аларга ничек шалтыратып, нидер кушыйм инде? Яшермим, ачуланучылар, үпкәләүчеләр бар. Әмма аңлыйлар.
– Җитәкче буларак, төп кагыйдәгез нинди?
– Иң мөһиме – дисциплина. Барысы да шуннан башлана. Анысы бар икән, кешелеклелек тә була.

кайтаргыч элементы булган кием киярга кирәк. Инде балаларга да сөйлибез: әти-әниләрен дә шуңа өйрәтсеннәр, дибез. Менә минем тәҗрибәмнән бер очрак. Машина җәяүлене бәрдергән. Автомобиле төзек, йөртүчесе аек. Видеорегистраторыннан карыйбыз: юлга чыккан кеше соңгы мизгелдә генә күренә. Мондый очракта машинаны берничек туктатып өлгереп булмый.

Быелның 10 аенда Татарстанда 790 җәяүлене машина таптатты. Узган елгыдан 32гә азрак бу. 749ы (–23) имгәнде, кызганыч 65 (–3) кеше һәлак булды. Төнлә машина астына эләгеп, 234 кеше имгәнде (+1), 42 кешенең гомере өзелде (–7).

Кагыйдә бозган кешеләргә штраф салу турында сөйләп тә торасым килми. Эш бит штрафта түгел, кеше гомере мөһим. Әле менә Арча районында бер вакыйга булды. Безнең инспекторлар юлдан барган җәяүлене туктата. Төнлә бу. Теге кап-кара киемнән. Машиналарыннан алып, моның өстенә яктылык кайтаргыч жилет кигезәләр, озатып калалар. Озак та үтми, ярамаган урында юлны чыккан да бу кешене машина бәрдереп китә.

Яктылык кайтаргыч элементлар турында күпме сөйлибез, ә тирә-ягыбызга күз салыйк әле: андый кием кимибез бит. Ничек тә шуны гадәти күренеш итәсе, модага кертәсе иде. Бигрәк тә балалар, яшьләр арасында. Шәһәр яки авыл эчендәме, зур юлдамы, бөтен җирдә файдасы бар аның. Ялгышмасам, Белоруссиядә шундый закон кертеләр, зур штраф билгеләделәр. Нәтиҗәдә машина астында тапталып үлүчеләр нибары бер ел эчендә 70 процентка кимеде. Финляндиядә андый элементларны хәтта мөгезле эре терлеккә ябыштыралар яки буяп куялар. Юк икән, җәзага тарталар. Хайван түгел, кеше гомерен кайгырту бит бу.

:: Без әле ярамаган урыннар турында сөйлибез. Җәяүле кичүләрендә дә куркыныч сагалап тора. Әйе, колакчын кигән, башын капюшон белән каплаган кеше, кагыйдә буенча, хаклы. Аңа юл бирелергә тиеш. Әмма төрле хәлләр була: машина бит туктый алмаска да мөмкин. Ә инде куркыныч хәл килеп чыккач, синең хаклы булуың кемгә кирәк?
– Игътибар кирәклеген бары тик аңлату эше белән генә җиткереп була. Шул исәптән, сезнең, ягъни матбугатның ярдәме белән дә. Чит илләрнең тәҗрибәсен дә өйрәнәбез. Аларда да шул ук хәлләр. Беребез дә үлемсез түгел. Тиеш урында чыкканда да башта як-ягыңа карарга кирәк. Бозлавыкта машина туктый алмаска, башка хәлләр килеп чыгарга мөмкин.

:: Белоруссия димәктән, соңгы вакытта чит илдән машина алып кайтучыларның артуы сизелә. Аларга нинди киңәш бирер идегез?
– Мондый автомобильләрне тиешенчә теркәргә кирәк. Әйтик, Абхазия номерлары белән йөргән бик күп машиналар туктатыла. Ул машиналар ябып куела. Хуҗаларына мәсьәләне таможня органнары белән хәл итәргә туры килә. Кагыйдә бозгач, штраф түләмәс өчен, теркәлмичә йөрүчеләр бар. Әмма штрафтан котылып булмый, алар теркәлеп бара, барыбер түләргә туры киләчәк.

Быел 10 айда чит ил теркәү номерлары куелган транспорт белән идарә иткән кешеләргә карата тизлек режимын бозган өчен административ хокук бозу турында 1400 беркетмә төзелде. Кагыйдә бозу очраклары камералар тарафыннан ачыкланды.

:: Казанда тагын бер замана хикмәте – самокат проблемасы хәл ителдеме?
– Проблема бөтенләй хәл ителде, дип әйтә алмыйм, әмма башкарган эшнең нәтиҗәсе бар. Бу мәсьәләне Татарстан буенча эчке эшләр министры Артем Хохорин контрольдә тотты. Арендага самокат бирүче оешмалар белән зур эш башкарылды. Алар безне ишетте, таләпләрне үтәделәр. Элек кайда телиләр, шунда ташлап калдыралар иде. Хәзер махсус парковкалар ясалды. Мәктәпләр, җәяүле кичү урыннарында тизлекне киметә яки бөтенләй туктата торган программалар урнаштырдылар. Казан хакимиятенә дә, Чаллы җитәкчелегенә дә рәхмәт. Анда арендага самокат бирүче оешмалар бөтенләй юк.

:: Сез йөртүчеләр әзерләү эшеннән канәгатьме? Ник дигәндә, кешене газ белән тормозга басарга өйрәтәләр, кагыйдәләрне ятлаталар. Тик аварияләр бит боларны белмәү аркасында гына килеп чыкмый. Килешәсездер, төп проблема кешенең холкына барып тоташа. Ул тормышта нинди – үзен юлда да шулай тота.
– Без Татарстандагы автомәктәпләрнең рейтингын төзибез. Ни өчен? Аларны контрольдә тоту максатыннан, дөрес укытсыннар, бу эшне җаваплы итеп башкарсыннар өчен. Мин сезнең белән килешәм, кешенең холкы аның юлда үз-үзен тотышында да чагыла. Автомәктәпләр автоклуб кына түгел. Алар рульдә йөрүнең писхологик якларына да күбрәк игътибар бирергә, юлда бер-береңне хөрмәт итәргә өйрәтергә тиеш.

Әңгәмәдәш – Илнар ХӘСНУЛЛИН

Әтисез яшәп кара син!

Уйлы күңел уйлана

Авылыбызда мәчет ачылганчы һәм әле ачылгач та, имам табылганчы, бу вазыйфаны күрше Салавычтан Габделфәрт абый Латыйпов үтәде. Бик көр һәм яңгыравыклы тавышы белән ул әйткән азан ике авылны да моңга күмә, ул укыган Коръән аятьләре күзләргә яшь китерә иде. Габделфәрт абый теләкләрендә һәрчак: «Патшалар күңеленә миһербан бир», – дип әйтә, ил, республика, район, авыл җитәкчеләрен дә онытмый иде. Шул чакта күңелгә «әллә кайдагы патшалар күңеленә миһербан теләмәсә дә була бит инде» дигән көфер уйлар да килә иде. Тормыш аның никадәр хаклы булуын күрсәтте...

2014 елгы Украина мәҗаралары башланган чакта әни әле телевизордан яңалыклар, һава торышы, юк-юк та татарча концертлар карый иде. Шөкер, соңгы ике елда карамый һәм бүгенге хәлләрне белми. Телевизордагы яңалыкларны ачсаң, анда гел шул Украина хәлләре. Шуны күргән саен әни: «Бетми торган нинди чуалыш булды инде бу, сугышлар китереп чыгара күрмәсеннәр. Аллаһ сакласын, кияүләр бар, оныклар үсеп җитте», – дип курка, аннан озаклап, теләкләр тели. Ә мин, белдекләләнеп, билгеле, аны тынычландырырга теләп: «И әни, борчылма, хәзер теге заман түгел инде, сугыш булса, кеше чакырып тормыйлар, төймәгә басып кына сугышачаклар, кораллар бик көчле», – ди идем.

Урамда егерме беренче гасыр шул. Мондый хәлгә, бу чиккә килеп җитәр, китереп җиткерерләр, дип һич тә ышанмадык. Кем гаепле, кем гаепсез дип тикшереп утырудан бүген берни дә үзгәрми, күңел фәкать бу чиккә җитәргә тиеш түгеллеген генә аңлый. Вакытында уртак тел табарга ярдәм итүче көчләр табылмады. Хәер, ике ил арасында түгел, әле гаиләдә генә аңлашылмаучанлык булса, ике якны да ыскытучылар табыла. Бүген дә бер генә ил дә туктату өчен тырышмый, миңа калса, утка май гына сибәләр. «Агач башын җил бутый, кеше башын сүз бутый» дигән халык мәкален дәвам итеп, илләр башын патшалар бутый, дип өстәргә генә кала.

Һөнәрем буенча Бөек Ватан сугышы ветераннары белән күп аралашырга, истәлекләрен язарга туры килде. Баштагы елларда аларның барысы да диярлек: «Сугышка үз теләгем белән киттем», – дип сөйли иде, соңга таба бары: «Барасың киләме, дип сораучы булмады», – ди башладылар. Гаҗәп, әмма факт: повестка килгән, киткәннәр, хәзер дә бик күпләр «эһ» тә дими китә. Юкса, инде кимендә өч-дүрт буын алмашынган, чоры да башка... Акыл белән аңлап, кабул итеп тә булмый кебек.

Ул чакта киткәннәрнең дә, калганнарның да ниләр кичергәнен аңлыйбыз кебек тоела иде. Бу хакта күпме хисләнеп, мәктәп елларыннан иншалар, аннан күп сандагы язмалар яздык. Тик... тамчы да аңламаганбыз икән! Бу көз аңлатты. Озатучылар ир, әти, бала, гаилә кадере турында, китүчеләр әти-әни, хатын, бала кадере турында уйланды. Беркемә китмәгәннәр дә шушы хисләр белән йокларга ятты, шунык белән торды. Әйтерсең барыбыз да күпьеллык йокыдан уяндык. Без инде, барысы да гел шушылай ипле генә барыр, дип уйлаган идек. Тыныч тормышның кадерен, түмен белгән өлкән буын ихлас күңелдән, ил-җирләргә иминлек бир, сугыш афәтләрен күрсәтмә, дип теләгәндә дә, әйдә, әйтсеннәр инде, дигәндәй, битараф кына тыңладык, бүген мондый хәлләр булыр дип уйлый белмәдек.

Динебез, барлык авырлык-сынаулар да юктан бирелми, дип өйрәтә. Бездә инде барысы да буталып беткән, ата – улны, ана кызны белми торган чорда яши идек. Күп зарландык, булганның кадерен белү, шөкер итү хисләре дә югалган иде кебек... Бүген күрегез: социаль челтәрләрдә ике кешенең берсе шушы кыйммәтләр турында шигырь яза, бөтен кеше диярлек иртә таңнан ил-көннәргә тынычлык теләп, хәбәрләр җибәрә...

Районыбызның бер мәктәбендә, әтисе өлешчә мобилизациягә чакырылганнан башлап, башлангыч сыйныфта укучы бала көн саен диярлек укытучысына бер сорау биргән: «Минем әти кайчан кайта?» Укытучысы ниләр дип җавап биреп бетергәндер, әмма өч балалы ир бер айдан Казаннан борылып кайта. Әй, сөенә сабый! Аның: «Әти кайтты!» – дип, үрле-кырлы сикерүен күреп, бер сыйныфташы түзми: «Чистый мактандың инде әтиең кайту белән», – ди. «Мактанырсың да, – ди теге сабый. – Бер ай әтисез яшәп кара!» Бер ай әтисез яшәүнең ни икәнен хәтта балалар да аңлый башлады. Аны әле ятимнәр, толлар гына аңлый иде...

Тагын бер уйландыра торган хәл Филүс Каһировның шактыйдан бирле җырлый торган «Киек каз юллары» җыры белән килеп чыкты. Бу яңалык түгел. Тарихын язарга җыенмыйм. Әмма шушы җырның, аны башкаручы Артур Хәсәновның популярлык казануының сере дә шушы вакыйгаларга, күңел халәтенә бәйле кебек тоела. Сүз дә юк, Артур матур җырлый. Филүс башкаруында яратып өлгергән бу җырны ул башка вакытта җырласа, иманым камил, ул мондый яңгыраш алмас иде. Хәрби җыйналу урынында, хәрби киемнән җырлаганга, йөрәктәге моңга авазадаш булганга, һәр сүзе бүгенге көнгә тәңгәл килгәнгә, сабый балалардан алып, өлкәннәргә кадәр һәркемнең күңелен парә-парә телгәләде ул. Башка төрле җыр җырласа да, бу кадәр популярлык казанмас иде кебек тоела. Бәлки, ялгышамдыр.

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

«Татар-информ»

14 ноябрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!»12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». (Татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.30 «Татарстан без коррупции» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Каравай». Цветария 6+
00.15 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 «Татар теле дәресләре» 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Шамил Бариев турында телеочерк (субтитрлы) 6+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20 «Йөрәктән – йөрәккә». Шамил Бариев турында телеочерк (субтитрлы) 6+
19.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Шамил Бариев турында телеочерк (субтитрлы) 6+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Памяти Сергея Пускепалиса. «ШИФР». Новые серии (S) 16+
22.40 «Большая игра» 16+
23.40 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Павел Трубинер, Екатерина Вилкова, Игорь Петренко, Мария Машкова, Сергей Маховиков, Константин Милованов. «БАРЕНЦЕВО МОРЕ» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
03.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 Профессиональный бокс. Умар Саламов против Викапиты Мероро. Трансляция из Казани 16+
07.00, 10.00, 12.55, 14.50, 17.20, 22.30 Новости
07.05, 14.20, 19.00, 21.45, 00.35 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 02.45 Специальный репортаж 12+
10.25, 15.25 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20, 04.05 «Катар. Обратный отсчёт» 12+
14.55 «География спорта. Кольский полуостров» 12+
16.15 «Громко» Прямой эфир
17.25 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Луч» (Москва). Прямая трансляция
19.15 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» (Москва) – «Спартак» (Москва). Прямая трансляция
22.35 Бильярд. «BetBoom Лига Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы.
00.05 Тотальный футбол 12+
01.15 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Пермские медведи» (Россия) – «СКА Минск» (Белоруссия) 0+
03.00 Новости 0+
03.05 «Несвободное падение. Олег Коротаев» 12+
05.00 «Громко» 12+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Игорь Стам, Вера Шпак, Александр Тютин. «СПЕЦБАТ» (S) 16+
22.00, 00.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
00.25 Максим Дрозд. «БЕГЛЕЦЫ» 16+
02.05 Сериал «ЗВЕРОБОЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «6 кадров» 16+
06.45 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.20 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.35 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». «Невидимая няня» 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «БАРХАТНЫЙ СЕЗОН» 16+
19.00 «ПО ТУ СТОРОНУ СОЛНЦА» 16+
23.00 «Порча». «Непосильная ноша». «Кнопка вызова» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.35 «Верну любимого» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.50 «ВОСТОК-ЗАПАД» 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
04.25 «ТЕМНЫЙ ИНСТИНКТ» 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 01.00 «НЕУЛОВИМЫЕ МСТИТЕЛИ» 12+
10.55, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «СМЕРШ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Оружие холодной войны». Док. сериал. 1-я серия 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Святой Лука. Хирург от бога» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ГОНКА С ПРЕСЛЕДОВАНИЕМ» 12+
02.20 «Набирая высоту. Истории про больших мечтателей». Док. фильм 16+
03.20 «КАДЕТЫ». 1-я и 2-я серии 12+

15 ноябрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
11.00 «Азбука долголетия» 6+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». (Татар телендә) 16+
13.00 «Родная земля». (Татар телендә) 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – Казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 6+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Газиз Айдарский 12+
00.45 «Каравай». Поэзия русского костюма 6+
01.10 «Татар теле дәресләре» 6+
02.00 «Манзара» 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Яралы язмышлар». Фәтхерахман Әхмәдиев 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 21.25 «СИНЕҢ КҮЗЛӘР» 12+
19.05, 22.05, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ШИФР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Павел Трубинер, Екатерина Вилкова, Игорь Петренко, Мария Машкова, Сергей Маховиков, Константин Милованов. «БАРЕНЦЕВО МОРЕ» 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
03.00 Детективный телесериал «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ
06.00 «Есть тема!» 16+
07.00, 10.00, 12.55, 16.20, 22.30 Новости
07.05, 14.20, 21.45, 00.25 Все на Матч! Прямой эфир
10.05, 13.00, 00.05 Специальный репортаж 12+
10.25, 16.25 Еврофутбол. Обзор 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
13.20, 04.05 «Катар. Обратный отсчёт» 12+
16.55 Мини-футбол. Чемпионат России. PARI-Суперлига. «Синара» (Екатеринбург) – «Торпедо» (Нижегородская область). Прямая трансляция.
18.55 Хоккей. OLIMPBET Чемпионат МХЛ. «Крылья Советов» (Москва) – «СКА-1946» (Санкт-Петербург). Прямая трансляция
21.15 «География спорта. Кольский полуостров» 12+
22.35 Бильярд. «BetBoom Лига Чемпионов». Прямая трансляция из Москвы
01.05 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС (Казань) – «ПАРМА-ПАРИ» (Пермский край) 0+
03.00 Новости 0+
03.05 «Несвободное падение. Кира Иванова» 12+
05.00 «Правила игры» 12+
05.30 «Наши иностранцы» 12+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Остросюжетный детектив «СПЕЦБАТ» (S) 16+
22.00, 00.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
00.20 Премьера. «Англия – Россия. Коварство без любви». «Мокрая» дипломатия» 16+
01.20 Сериал «ЗВЕРОБОЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча». «Ночная жизнь» 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «ЮРОЧКА» 16+
18.45 «Про здоровье» 16+
19.00 «НЕСКОЛЬКО ДНЕЙ ИЗ ЖИЗНИ ДОКТОРА КАЛИСТРАТОВОЙ» 16+
23.00 «Порча». «Чёртово перо». «Куколка» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.35 «Верну любимого» 16+
01.00 «Понять. Простить» 16+
01.50 «ВОСТОК-ЗАПАД» 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.00 «КАДЕТЫ». 3-я и 4-я серии 12+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.15, 01.05 «НОВЫЕ ПРИКЛЮЧЕНИЯ НЕУЛОВИМЫХ» 12+
10.55, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «СМЕРШ. КАМЕРА СМЕРТНИКОВ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
17.35, 04.40 «Москва фронту». Док. сериал 16+
18.50 «Оружие холодной войны». Док. сериал. 2-я серия 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «ВЕСЕННИЙ ПРИЗЫВ» 12+
02.25 «ГОНКА С ПРЕСЛЕДОВАНИЕМ» 12+
03.55 «Панфиловцы. Легенда и быль». Док. фильм 12+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 14–20 НОЯБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Бу атнада күптәнге бер эшегезне төгәлләп, гаять зур рухи һәм матди канәгатьлек кичерерсез. Җитәкчегез белән бераз гына үзара каршылык килеп чыгар шикелле. Тәмле телегезне кызганмасагыз, барысы да сезнең файдага төгәлләнер.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Ниятләгәннәрнең барысына да өлгереп булмау сәбәпле, бераз дулкынланып алырга туры килер. Горурлыкны җиңеп, тирәгездәгеләрнең ярдәменә дә таянырга кирәк булыр. Киләчәгегезгә йогынты ясардай мөһим бер яңалык ишетелер.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Үзең утырган ботакны кисмә, дигән гыйбарәне искә алып, бик дөрес карарга килерсез. Кызыклы, ә иң мөһиме – акчалы эш тәкъдим итмәгәйләре. Ял көннәрендә шатлыклы вакыйга көтегез.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Эшнең нечкәлекләрен белеп бетермәү сәбәпле, уңайсыз хәлдә калуыгыз бар. Шуңа күрә, бик кирәкмәсә, тегендә-монда кысылып йөрмәгез. Кыш алдыннан өс-башны карау теләге байтак кына чыгым белән төгәлләнер.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Берара тышкы кыяфәтне тәртипкә салуга кагылышлы бәйләнчек уйлар йөдәтеп алыр. Әйтик, прическаны үзгәртергәме-юкмы, мех якалы җылы куртканы алыргамы-юкмы, дип башыгызны катырырсыз. Хезмәттәшегез ачкан бер сер шаккатырыр.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Ниһаять, эшегездә уйларыгызның җыйнак, сүзләрегезнең төпле икәнен, үзегезнең акыллы булуыгызны аңлаучылар барлыкка килер. Бу бик күңелле хәлләр белән төгәлләнер. Өстәвенә әле атна ахырында сөенечле хәбәрләр дә ишетелер.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Бер максатыгызга ирешүдә зур гына сынау аша узарга туры килер. Үзегезгә бик кирәкле әйберләрне аңларга, кызыклы гына нәтиҗәләр ясарга булышыр бу. Атна ахырында тормышыгызга яңа сулыш өреп җибәрердәй хәлләр көтегез.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Өстегезгә авыр йөк булып төшкән проблемаларны искиткеч дәрәҗәдә җиңел хәл итеп, иркенләп сулап куярсыз. Эшегездә һич көтмәгәндә «ялтырап» алуыгыз абруегызның үсүенә китерер. Уйламаган җирдән табыш керер.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Эштә килеп туган хәлне бик тиз аңлап, яшен тизлегендә дөп-дөрес карарга килерсез. Бу, әлбәттә, җитәкчегез игътибарыннан читтә калмаячак! Атна уртасында ишетелгән әйбәт яңалыклар рухландырып җибәрер, ләкин аларның чынмы-түгелме икәнен тикшереп карау зыян итмәс.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Ничәмә-ничә еллар буе тынгылык бирмәгән бер максатыгызга ирешерсез. Кайберәүләрнең борынына чиертердәй уңышлар көтегез. Аларның матди ягы бигрәк тә сөендерер.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Матди хәлегезнең яхшыруына өметләндерерлек хәбәрләр ишетерсез. Укымыйча гына рәсми кәгазьләргә кул куймагыз: нечкәлекләре игътибардан читтә калырга мөмкин. Бердәнберегезнең матур һәм бик кирәкле бүләгенә балаларча сөенерсез.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Акчалы, бик бай чор. Эштәге проблемаларыгыз да тыныч һәм җиңел хәл ителер. Шулай итеп, күңелегез күтәрелеп китәр, башыгызга яңа уй-планнар килер.

ҺӘРЧАК ИГЪТИБАР СОРЫЙ

Югары булуы да, нормадан түбән төшүе дә куркыныч. Кандагы холестерин күләме турында сөйләгәндә, табиблар шулай дип кисәтә. Күбебез бармак аша караса да, чынлыкта аны даими рәвештә контрольдә тотарга кирәк, ди белгечләр.

Кандагы холестеринның без белгән һәм белмәгән үзенчәлекләре турында табиб-терапевт Гөлназ ШӘЙДУЛЛИНА сөйләде.

➤Холестерин, нигездә, бавырда барлыкка килә торган, организмның яхшы эшләве өчен әһәмиятле булган майдан (липид) гыйбарәт. Аның яртысын организм үзе эшләп чыгара, калганы ашаган ризык белән керә. Холестерин безнең организмга ферментлар, гормоннар һәм башка элементлар барлыкка китерү өчен кирәк.

➤Рәсми саннарга ышансаң, Россиядә яшәүчеләрнең нибары 5 проценты гына кандагы холестерин күләмен даими тикшертеп, контрольдә тота. Чынлыкта, холестерин нормаларын һәркем белергә тиеш. Холестерин:

яхшы – 5 ммоль/л;
аз гына югары – 5 һәм 6,4 ммоль/л арасында;
уртача югары – 6,5 һәм 7,8 ммоль/л арасында;
бик югары – 7,8 ммоль/л дән артык.

➤Бүген кешеләр аз хәрәкәтләнә. Бу исә, үз чиратында, канда холестерин күләме артуга бер сәбәп булып тора. Тәмәке тарту, исерткеч эчемлекләр белән мавыгу, даими рәвештә стресс кичерү дә бу куркынычны арттыра. Артык авырлыктан, шикәр чиреннән интеккән, майлы ризыклар ашарга яраткан кешенең дә, гадәттә, холестерины югары була. Ир-атларда холестеринның нормадан югары булуы ешрак күзәтелә. Хатын-кызларда исә ул еш кына менопауза чорында яки әни булырга әзерләнгәндә югары була.

➤Нормадан артып китсә, ул кан тамырлары стеналарына утыра башлый. Нәтиҗәдә, кан агышы начарлана, кан тамырында төерләр барлыкка килә. Бу исә инфаркт, инсульт куркынычын арттыра. Атеросклероз (артерияләрнең кысылуы һәм тыгызлуы) очраклары арта. Кандагы холестерин күләме югары булганда кешенең йөрәк тибеше начарлана, аяклары сызлый, тән тиресендә сары таплар, күз тирәсендә каты төерләр пәйда була.

➤Холестеринны төшерү өчен, иң беренче чиратта, начар гадәтләрдән баш тартырга, гәүдә авырлыгын контрольдә тотарга, табиб билгеләгән даруларны эчәргә кирәк. Составында трансмайлар булган ризыклардан баш тартып, клетчаткалы ризыкларга өстенлек бирү дә файдага булачак. Атнага ике тапкыр балык ашаган кешенең дә холестерины нормага килә.

➤Нормадан түбән булуы да куркыныч. Ул еш кына диеталар белән мавыккан, гемоглобины түбән булган, стресс кичергән кешедә күзәтелә. Холестерин түбән булганда кешенең аппетиты югала, ул тиз арый. Андый чакта сөяк сыну очраклары да еш күзәтелә.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Абау!

Акрын үсүе сагайтсын

Аяк тырнаклары акрын үсү кандагы холестерин күләме бик нык артуны аңлата икән. Галимнәр шундый нәтиҗә ясаган. Алар уздырган тикшерену нәтиҗәләреннән аңлашылганча, холестерин кушылмалары кан тамырларын тарайта, кан әйләнешен чикли. Шуңа күрә ниндидер актив эштән соң авыру кешенең балтыр мускулларын көзән җыерырга мөмкин. Холестерин күләме югары булганда йөрәк-кан тамырлары авырулары барлыкка килү, кан тамырлары тыгылу куркынычы арта. Бу инсульт һәм йөрәк өянәге китереп чыгарырга мөмкин. Мондый өзлегүләр булмасын өчен, актив тормыш алып барырга, составында туендырылмаган майлар булган ризыкларны күбрәк ашарга киңәш итә табиблар.

НИЧЕК ТУКЛАНЫРГА?

Холестеринны төшерә торган ризыклар	Холестеринны күтәрә торган ризыклар
авокадо, көнҗет, көнбагыш, пестә чикләвеге, кабак орлыгы, әрбет чикләвеге, бадәм, зәйтүн мае, балык мае, җиләк, мүк җиләге, нарат җиләге, гранат.	кызыл ит, йомырка, казылык, майонез, консервланган ризыклар, баллы тәм-том, кыздырылган ризык, маргарин, кофе, фастфуд, сөт ризыклары.

Тамакка да, аякка да шифалы

Эремчектә аксым, май, кальций тозлары, фосфор күп. Эремчек бавырга май җыелуны, тукымалар тыгызлануны булдырмый. Әмма әлеге сөт ризыгында бавыр юлларында тупланучы терлек мае күп. Шуңа да эремчекне даими ашаганда аңа үсемлек мае өстәргә киңәш ителә һәм эремчекнең майсыз төрләрен сатып алу яхшырак.

Эремчек үзләштерелсен өчен, ашкайнату системасының барлык әгъзалары да күп көч куярга тиеш була. Шуңа да аны көнгә 200 граммнан артык ашарга киңәш ителми. Эремчек бал, теләсә нинди җиләк-җимеш, җиләкләр, яшелчә,

чикләвекләр белән дә тәмле. Эремчекне пешермичә ашау файдалы.

Тамак авыртса. 200 грамм эремчеккә башлы 2 суган турагыз. Әгәр эремчек салкын икән, аны җылытыгыз һәм артык суын сыгып алгач, муенга куегыз. Мондый дәвалау бәйләвечен берничә сәгать тотарга да, төнгелеккә калдырырга да мөмкин.

Аяклар даими шешенсә. Авырткан урынга эремчекле бәйләвеч кую ярдәм итә. Эремчек корырак булса яхшы. Бер сантиметр калынлыкта эремчек сылаган бәйләвечне көндез 3–4 сәгатькә куегыз. Шулай 2 атна дәваланырга кирәк. Көн аралаш аны вак угычтан уылган бәрәңге белән алмаштырырга мөмкин.

Ашказаны ачылыгы югары булганда. 100 грамм эремчеккә 1 стакан катык, 1/4 стакан сөт салып болгатыгыз да 2–3 сәгать караңгы урында тотыгыз. Ашаганнан соң 40 минут үткәч, аны 3әр аш кашыгы ашагыз.

Тест

ОРГАНИЗМГА МАГНИЙ ҖИТӘМЕ?

Кулларыгыз һәрчак корымы?
•кулларым һәрчак дымлы була (2 балл);
•әйе (0);
•кайчан ничек инде (1).

Аз калорияле диеталарда утырасызмы?
•әйе, даими рәвештә (2);
•булгалый (1);
•беркайчан утырганым юк (0).

Кузаклы үсемлекләрне (ногыт борчагы, борчак, ясмык) айга бер тапкырдан да азрак ашыйсызмы?
•төрлечә була (1);
•әйе (2);
•юк, кузаклыларны һәрдаим ашыйм (0).

Шпинат, яшел ногыт борчагы кебек яшелчәләрне хәтта җәй көне дә атнасына 3 тапкырдан азрак ашыйсызмы?
•әйе (2);
•юк (0);
•кайчан ничек туры килә (1).

Кыздырыр алдыннан бәрәңгене суда озак тотасызмы?
•әйе, берничә сәгать суда тотканнан соң гына кыздырам (0);
•чистартуга ук кыздырам (2);
•төрлечә була (1).

Төнлә аягыгызны көзән җыерганы бармы?
•юк (0);
•бик еш (2);
•кайчак булгалый (1).

Ризык сайлаганда составында минераль матдәләр булу-булмауга игътибар итәсезме?
•һичшиксез (0);
•составын карарга онытকан чаклар да була (1);
•беркайчан игътибар иткәнем юк (2).

НӘТИҖӘ

0–10 балл. Организмыгызда магний җитәрлек. Дөрес туклану һәм сәламәт яшәү рәвеше нәтиҗәсе бу!

10–15 балл. Магний запасы акрынлап кими бара! Соңгы арада стрессларга тизрәк бирешә башлавыгызны үзегез дә сизгәнсездер. Шуңа күрә тынычлык сакларга тырышыгыз, организмга физик яктан авырлык китерүдән дә саклагыз. Магнийга бай кешью, бадәм, фундук, кыздырылган көнбагыш, карабодай ашарга һәм минераль су эчәргә киңәш ителә.

15–24 балл. Организмыгызга магний җитми, вакытында чарасын күрмәсәгез, бу ашказаны, йөрәк эшчәнлегенә зыян салачак. Көзән җыеру да күзәтелергә мөмкин. Мондый очракта кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итегез!



Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ИРТӘНГЕСЕН КАЛДЫРМА

Табигать кануннары буенча, организм, көз җитүгә, суыкларга әзерләнә: гәүдәгә май җыела башлый. Көннәр кышка авышкач, витаминнар җитми, йокымсырата, тиз алҗыта. Диетолог Нәҗия Хамматова, мондый хәлгә юл куймас өчен, иртәнге ашны беркайчан калдырмаска, һәм аны дөрес ризыклардан гына әзерләргә киңәш итә.

Көннәребез, вакыт юклыкка сылтап, иртән бер чынаяк чәй яки каһвә белән генә чикләнә. Вакыт тар икән, җиңелчә ашны кичтән үк әзерләп калдырырга мөмкин. Иртән аппетитны ачу, канны кудырып җибәрү өчен, бер стакан җылы су эчүдән дә яхшысы юк, ди Нәҗия ханым. Төнгә каршы авыр эшкәртелә торган ризыкны авызга алмаска, гомумән, кичке алтыдан соң ашамаска кирәк. Иртән аз гына ачыгу хисе белән йокыдан тору яхшы. Диетолог әйтүенчә, иртәләрен җиңелчә ризык әзерләргә вакыт тапмасагыз, үзегез белән эшкә алып бару өчен уңайлы ризыклар – смузи (блендерда яшелчә яки җиләк-җимешне изеп, сөт яки сок белән болгатып ясалган эчемлек), запеканка әзерләгез. Файдалы иртәнге рецептлар белән дә бүлеште Нәҗия Хамматова.

vk.com

Файдалы иртәнге ашлар

СОЛЫ КОЙМАГЫ

Нәҗия Хамматова әйтүенчә, клетчаткага, кальций, магний, цинк һәм фосфорга бай, организмнан токсиннарны чыгаруга ярдәм итүче ризык бу. 3 аш кашыгы геркулесны кофетарткычта ваклыйбыз. 1 йомырка һәм 60 мл сөт өстәп болгатабыз. Катнашманы аз гына майланган табага салып, ике ягы да алсу төскә кергәнче, әйләндерә-әйләндерә пешерәбез.

СЫР ҺӘМ ЙОМЫРКА БЕЛӘН БУТЕРБРОД

3 йомырканы сытып, шуңа 1 аш кашыгы сөт, яшел тәмләткеч (ваклап), тәменчә паприка өстибез һәм күпертәбез. Тәменчә тоз салабыз. Йомырка тәбәсенең ике ягын да кыздырып алабыз. Алты икмәк телемен кетердәп торырлык итеп кыздырабыз. Икмәк телеменә йомырка тәбәсе, сыр уып салабыз һәм икенче телем белән каплыйбыз. Тавыкның түш итен дә өстәргә мөмкин. Өч бутерброд килеп чыга. Сыр эрегәнче, мичтә тотабыз. Мондый бутербродлар A, E һәм B төркемендәге витаминнарга бай.

Кышын безнең алда артык авырлык җыймау бурычы тора, ди диетолог. Шуңа күрә елның суык чорында иртәнге ашның әһәмияте гаять зур. Дөрес итеп әзерләнгән иртәнге аш беркайчан да тазартмый. Тәмле ризыклы көз һәм кышлар сезгә!

ЯЛКАУЛАРЧА СОЛЫ БОТКАСЫ

Ул кичтән әзерләп калдырыла. Ярты литрлы банкага 100 г солы лачаулары, 60 мл кефир яки йогырт, 60 мл сөт, 1 туралган банан, кипкән җимеш, җиләк, тәменчә бал салып болгатабыз. Болгатканнан соң, капкач белән каплыйбыз һәм төнгә суыткычта калдырабыз. Иртән, банканы ачып, ботканы микродулкынлы мичкә куеп җылытабыз. Бу ризык та, солы коймагы кебек, клетчаткага бай, начар холестеринны чыгара, тиз генә ачыктырмый.

Мүк җиләге + гранат

Боларда кышын иммунитетны ныгыту өчен кирәкле антиоксидантлар «мыкгып» тора. Смузи өчен 100 грамм гранат бөртеге, 40 грамм мүк җиләге, 120 грамм йогырт, 1\4 стакан сөт кирәк. Барысын бергә блендерга салып болгатабыз.

Җиләк + көнҗет

Катырылган теләсә нинди җиләк кулланырга мөмкин. Блендерга җиләк, 100 грамм гранат согы, 100 грамм су, ярты аш кашыгы көнҗет орлыгы салып болгатабыз. Әзер эчемлеккә дә бераз көнҗет өстибез.

Алма + банан + дарчин

Бүлмәгә дарчин (корица) исе таралса, балачакта әниебезнең камыр ризыклары исен хәтерләтеп, күңелдә ниндидер бәйрәм хисе уяна. Сынап карагыз әле, чыннан да шулай! 1 кызыл алма, 1 банан, 5 миндаль чикләвеге, 100 грамм сөт, 150 грамм йогырт кирәк. Барысын да блендерга салып болгатабыз һәм дарчин (корица) өстибез.

Геркулес + хөрмә + кабак

Әфлисун төсендәге эчемлек үзе генә дә иртән кәефне күтәреп җибәрә! 5 аш кашыгы геркулеска 1 хөрмә, 1 стакан йогырт салып, блендерда болгатабыз.

Банан + хөрмә

Блендерга 1 стакан кайнар су, 1 банан, 3 хөрмә җимеше (финик), 1\4 аш кашыгы дарчин һәм бер чеметем ванилин салып болгатабыз. Кайнар килеш эчәбез.

Белеп тор!

ӘФЛИСУН ЧЕЛТӘРЕННӘН – ГУБКА

Цитрус җимешләр тутырып сатылган челтәрне савыт-саба юу өчен кулланырга мөмкин. Җыеп бәйләп куясың да менә дигән губка килеп чыга.

Тефлон табаны да, сыдырмыйча-тырнамыйча, бик әйбәт юачак ул.

Килешәме?

▶ Кечерәк гәүдәле кешегә очлы башлы туфли алу отышлырак. Мондый аяк киеме озынрак, сылурак итеп күрсәтә.

▶ Зур үлчәмдәге аяк киеме киясез икән, аякны кечерәйтебрәк күрсәтергә теләсәгез, башы җөй, бизәк белән яки башкача «аерып» куелганын карагыз. Нәкъ менә шундый туфли аякны җыйнаклындыра.

▶ Аяк тубыгы киң булган яки кыска аяклы кешеләргә тубыктан каеш белән эләктереп куела торган туфлидан баш тарту хәерле. Каеш, аякларны «кисеп», тагын да кыскарак итеп күрсәтәчәк чөнки.

Бакчачы почмагы

Кайчан төрергә?

Яшь агачларны кайчан һәм ничек төрергә? Гомумән, аларны кышка ничек әзерләп калдырырга икән?

Резедә ГАБДУЛЛИНА. Питрәч

Бакчачы Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә

– Яшь агачларны һава температурасы –3...–5 градус тирәсендә тирбәлә башлагач төрергә кирәк. Ике ел рәттән! Чөнки кайрылары бик юка булганлыктан, алар суыкта ярылырга мөмкин. Спанбонд, лутрасил кебек махсус материал булмаса, чүпрәк капчык, иске җәймә, юрган тышы белән төреп куярга мөмкин. Катыргы кәгазь белән дә урап куярга була. Куян, тычкан кимермәсен өчен, өстеннән рубероид, линолеум, поролон белән әйләндереп алыгыз. Ләкин агачка һава да кирәк, моның өчен ике арада бераз бушлык калдырыгыз. Язын температура –5 градус чамасы була башлауга, өске катламны алып ташларга кирәк.

Тамырларын суыктан саклау өчен, төбенә черемә, пычкы чүбе яки печән җәеп калдырырга онытмагыз. Катыргы салып калдырырга да мөмкин. Ул да суык үткәрми. Агач төбендә җирдә ярыклар күрсәгез, томалагыз. Юкса алардан тамырга суык төшәчәк.

Мең дә бер киңәш

ЙОМЫРКА КАБЫГЫН ТАШЛАМА

✓ Чәйнек яки термос эчен көзге кебек ялтыратып куюны серен беләсезме? Йомырка кабыгын, җылы су белән чайкаткач, савытка салыгыз һәм яртылаш су тутырыгыз. Әйбәтләп селкегез дә төнгә калдырыгыз. Иртән аның чип-чиста булып калуын күрәчәксез! Гомумән, ак төстәге йомырка кабыгы агарту үзлегенә ия.

✓ Йомырка кабыгын порошок хәленә килгәнче төеп, тукыма капчыкка тутырыгыз, авызын бәйләгез. Ак киемне юганда, капчыкны машина барабанына салыгыз. Керне агартачак ул!

✓ Йомырка кабыгын төеп, суга салыгыз һәм бер тәүлек тотыгыз. Төнәтмәне бүлмә гөлләренә сибегез. Кабыктагы файдалы матдәләр – бик әйбәт ашлама.

АТА АРКАСЫ – КАЛА АРКАСЫ

Әниләр турында күп сөйлибез, язабыз. Ә менә әтиләр читтә кала кебек. Ислам динендә әти хакы турында ни диелә? Әтиләрнең балалары каршында бурычлары нинди? Гаиләдә аңа нинди мөнәсәбәт булырга тиеш?

Әти хакы турында Артур хәзрәт ГАБДУЛЛИН белән сөйләштек.

:: Хәзрәт, әтиләрнең балалары каршында нинди бурычлары бар?

– Әнинең дәрәҗәсе югары булса да, әтинең дә гаиләдә мөһим урыны бар. Аллаһы Тәгалә дөньяга иң беренче китергән кеше ул – Адәм (г.с.). Дөньяга яшәргә дип килгән иң беренче кеше – ир-ат, димәк. Хәдистә болай диелә: «Һәрберегез – көтүче һәм һәммәгез дә көтүегез өчен җавап бирерсез». Шуннан чыгып та ир-атның гаиләсе өчен тотка икәнен аңлыйбыз инде. Ул – гаиләсен караучы, тотучы. Хатын алгач, бала тугач, ир-ат ир, әти ролен үти башлый. Аның өстенә зур җаваплылык ята.

Бурычларга килгәндә, иң элек – бала тугач аңа матур, мәгънәле исем бирү. Аннан соң – тәрбия. Яхшы, дини тәрбия бирү бик мөһим. Әйе, бу инде әтигә дә, әнигә дә кагыла. Балалар – синең нәселеңне дәвам иттерүчеләр. Син дөньялыктан киткәч, искә алып, дога кылучылар. Тәрбия бирмәдең икән, алай булмаска да мөмкин. Тагын бер бурыч – вакыты җиткәч балаларны башлы-күзле итү.

:: Хәзер, ни кызганыч, әти сүзе, авторитеты кими бара бит.

– Әйткәнебезчә, әнинең гаиләдәге роле ничек мөһим булса, әтинеке дә шулкадәр мөһим булып тора. Балалар үстергәндә аны тигеләй итмә, болай булма, дип өйрәтергә мөмкин ата-ана. Әмма, баласын тыеп та, үзләре шундый ук гамәлләрне кылырга мөмкиннәр. Бала моны күрә бит. Тәрбия кылганда бала синең сүзеңне тыңламый, ә сиңа карый. Син нинди буласың – ул да шундый булачак. Шуңа да балалар әтине өлге итеп күрергә тиеш. Ул нинди сүзләр әйтә, хатынына нинди мөнәсәбәттә, нинди гамәлләр кыла. Киләчәк нәселе яхшы булсын өчен, ир-ат көчле булырга тиеш. Ягъни аның гаиләдә ир буларак дәрәҗәсе булсын. Үзеңне ир-ат буларак тота белмисең икән, бала аны шулай тиеш дип үсәчәк. Элекке вакытларга күз салсаң, ир-атка мөнәсәбәт башкача булган. Хәзер, әйе, аларның гаиләдә сүзе үтми башлады... Хәзер кыйммәтләр үзгәрә, төрле агымнар барлыкка килә. «Феминизм» дигәнне дә яхшы беләбез. Шундый ысуллар белән ир-атның дәрәҗәсен, булмышын юк итәргә тырышалар. Бу – шайтан вәсвәсәсенә бирелү. Аллаһы Тәгалә ир-атны – ир-ат, хатын-кызны хатын-кыз итеп бар иткән бит. Чын бәхеткә алар бергә булганда, алар бер-берсен тулыландырганда гына ирешеп була. Аллаһы Тәгалә кануннарын бозарга ярамый. Әйтик, кунакта утырганда да күрергә мөмкин: кайбер хатын-кызлар ирләренә ямьсез дәшә, үзләрен бер баш өстен куя. Ир-ат башын иеп утыра инде ул. Кызганыч, әтинең, иренең дәрәҗәсе төшүендә хатын-кызның өлеше дә бар. Иргә ким булырга да, зур булырга да гүзәл затның бер сүзе җитә.

Әйтик, хатын иртән ирен эшкә уята. «Тор, нишләп ятасың, бүген дә соңга каласың инде», – дип, типкәләп диярлек куып чыгара. Ир-ат нинди теләк белән эшкә чыгып китсен һәм нинди теләк белән өйгә кайтсын? Ә шунда хатын: «Матурым, тор, ашарыңа әзерләп куйдым, эшкә барырсың, мин сиңа ышанам», – дип озатса? Булды! Ир-атка шул җитә. Моны, әйтүемчә, балалар да күрә.

Пәйгамбәребез (с.г.в) иң яхшы әти булган. Үз балаларына, хатынына мөнәсәбәтенә игътибар итсәк, хәйран калырлык. Әхлак ягыннан ул бик камил булган. Аның 7 баласы була, алтысы үзе исән чакта дөнья куя. Сынауларга карамастан, аның күңеле йомшак булып кала.

Илдар Мөхәммәтҗанов

:: Хатыннарын бала белән ташлап чыгып киткән «күке» әтиләр турында ни диярсез?

– Дин, әлбәттә, мондый күренешне хупламый. Ирне дә, хатынны да Аллаһы Тәгалә пар булсын өчен бар иткән. Хәзерге көндә күп ирләр хатыннарын ташлап чыгып китә. Бу инде ир-атның тәрбиясе булмаудан һәм гаиләсенә карата җаваплылык хисе тоймаудан килә. Ир-ат гаилә корыр алдыннан өстенә нинди җаваплылык ятканын аңларга тиеш. Аңламый икән, әнә шул гаиләдән китүне куркыныч бер хәл итеп санамый да ул.

Гыйбрәт ал

Адәм баласы ни өчен яралтылган?

Бер остаз шәкертләреннән:

– Сөекле шәкертләрем, ничек уйлыйсыз, Аллаһы Тәгалә кешене бу дөньяга ни өчен яраткан? – дип сорады.

Шәкертләренең берсе:

– Аллаһның рәхмәтен һәм ризалыгын алыр өчен, – дип җавап бирде.

Икенчесе исә:

– Гыйбадәт өчен яралтылдык, – дип җавап кайтарды.

Өченчесе исә:

– Изгелекләр эшләр өчен бу дөньяга яралдык без, – дип әйтте.

Остаз:

– Өчегезнең дә җавапларыгыз урынлы һәм дөрес, – диде.

Остазның бу сүзен ишеткән бер шәкерт:

– Хәзрәтебез, бу җаваплар ничек инде бөтенесе дөрес була алсын?! Алар бит бер-берсенә охшамаган, – дигән.

Остаз исә:

– Изгелек эшләсәк, гыйбадәт иткән булабыз. Гыйбадәт иткән булсак, Аллаһның рәхмәтенә һәм ризалыгына ирешәчәкбез, – дип җавап кайтарды.

Югарыдагы кыска гына кыйссага тирән мәгънә салынган. Адәм баласы, дөресрәге, акыллы кеше, бу дөньяга туганнан соң үзенә бер сорау бирергә тиеш: «Мин дөньяга ни өчен яралтылдым һәм ни өчен яшим?»

Хакыйкатьтә, бу сорауга җавап тапкан кешенең гомере тормышы матур, күңелле һәм бәхет эчендә узачак. Әгәр

tatarstan.ru

дә кеше, алтмыш-җитмеш яшен тутырып, дөньяга ни өчен килгәнлеген һәм ни өчен яшәгәнлеген белмәсә, ул үзенең гомерен бушка уздырган дип әйтсәк, ялгыш һәм хата булмас. Әйе, адәм баласы бу дөньяда изгелек эшләсә, гыйбадәт иткән була. Гыйбадәт иткән булса, Аллаһның рәхмәтен һәм ризалыгын алган була. Шушы гади генә әйберне үтәү кешенең каршысында бәхет ишекләрен ача. Бөтен хәсрәт, тынычсызлык ишекләрен каплап куя. Аллаһы Тәгалә рәхмәтеннән, ярдәменнән, дөрес, туры фикерле булудан безне мәхрүм итмәсен.

Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИНОВ

Йөгез, бер дога!

КИБЕТКӘ, СӘҮДӘ ҮЗӘГЕНӘ КЕРГӘЧ УКЫЛА

Ләә иләһә иллаллаһу вахдәһу ләә шарикәләһ, ләһул-мүлку вә ләһул хәмду йүхйи вә йүмиту вә һүә хәййүн ләә йәмүту, биядиһил-хайр, вә һүә галәә күлли шәйьин кадир.

Мәгънәсе: Аллаһыдан башка илаһ юк, Аның тиңдәше юк. Бөтен падишаһлык һәм мактау Аллаһы Тәгаләгә генә хас. Аллаһы Тәгалә терелтә һәм үтерә (ләкин Үзе һәрвакыт терек булып, бервакытта да үләчәк түгел). Барча хәерле эшләр Аллаһы Тәгаләдән һәм Аның көч-кодрәте бар нәрсәгә дә җитә.

Хикмәтле сүз

Гөнаһтан тәүбә итүче – гөнаһсыз кеше кебек.
Хакыйкатьтә, ачу килү – шайтаннан, ә шайтан уттан яратылган. Утны су белән сүндерәләр, шуңа күрә ачуы чыккан кеше тәһарәт алсын.
Дога – гыйбадәтнең җелеге.

Мәҗлес саваплы булсын өчен

- ➤Мәҗлес аш-суы хәләл булырга тиеш;
- ➤мәҗлес вакытында гайбәттән, ялган сүзләрдән тыелу кирәк;
- ➤ризык исраф булмасын;
- ➤вәгазь кешене ялыктырмасын;
- ➤вәгазь сөйләүче белемле, ихлас булсын.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук. Тулы, дөрес һәм беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

Газетабызның узган санында чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып кабаттан Казаннан ***Әминә Зарипова*** *танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Салават Фәтхетдинов башкаруындагы «Каен ауган», Зәйнәб Фәрхетдинованың «Әче-әче, диләр» җырларын, «Керфекләрең синең нигә кара?» дигән татар халык җырын яшергән идек.*

Берәүнең зәңгәр күккә карап, саный-саный кошларны озатып калуы һәм аларның парлап-парлап кайтасыларына өметләнүе турында бу җыр.

Әлеге җырда бер гашыйк җилгә иркәсен иркәләргә боерык бирә.

Мине ташлама, ялгыз итә күрмә, яңа тормыш башлама, ди җырчы. Сөйгәненнән гафу үтенә.

АКЧАМ ҖӘЛ ТҮГЕЛ СИҢА...

Владимир Путин Россиядә ана капиталы программасын озайтулары турында да искә төшерде. «Ел саен миллионга якын гаилә ана капиталы ала. Бу программа 2026 ел ахырына кадәр озайтылды», – диде ул. Киләсе елдан аның күләме дә артачак. Беренче балага – 590 мең сум тирәсе, икенче балага 780 мең сумга якын акча биреләчәк.

Эшлим дигәнгә – эш

Путин, эшлим, дип торган ата-анага тиешле шартлар тудырырга кирәклеген дә искәртте. «Эшкә чыгасы, квалификация күтәрәсе, яхшы хезмәт хакы түләнә торган яңа һөнәр үзләштерәсе килсен өчен, ата-анага өстәмә мөмкинлекләр һәм стимул булдырырга кирәк», – диде Президент. Эшкә чыккач яки керемнәре аз гына артып китүгә, ата-ананың балаларына түләнергә тиешле пособиедән еш кына мәхрүм калуын да әйтте ул.

– Бу мәсьәләне хәл итүнең берничә юлы бар. Иң элек салым түләүгә үзгәреш кертергә кирәк. Айлык кереме кимегән гаилә салымнарны азрак түләрлек булсын. Аларга пособиене дә өлешчә түләргә мөмкин, – диде Путин.

Алда телгә алган барлык эшләр Россиядә 2019 елдан бирле гамәлдә булган «Демография» илкүләм проекты кысасында башкарыла. 2024 елга кадәр дәвам итәчәк әлеге проект илдәге демографик хәлне яхшыртыр, дип өметләнәләр.

Сәрия
МИФТАХОВА

ЯРАМАГАН СҮЗ

БАЛАЛАРНЫ СҮГЕНҮДӘН НИЧЕК ТЫЯРГА?

Краснодар краенда сүгенгән өчен укучысына җәза биргән укытучы эштән китәргә мәҗбүр. Тәнәфес вакытында үсмернең авызына сыек сабын агыза ул. Теленә хуҗа булмаган яшьләрне мондый гамәл белән тәртипкә өйрәтеп булмаячагы көн кебек ачык. Алайса, нишләргә? Ярамаган сүзне өлкәннәр авызыннан ишетә бит ул.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Краснодар краендагы вакыйга сурәтләнгән видеоязма таралгач, интернетта зур бәхәс купты. Берәүләр – укытучыны, икенчеләр тәртипсез балаларны сүгә. Рус теле укытучысы коридорда начар сүз ычкындырган үсмерне туктатып, сабак бирмәкче була. Башта дөньякүләм танылган язучы Хемингуэй тормышыннан бер вакыйга сөйли. Баксаң, булачак язучының әнисе сүгенгән өчен улының авызын сабын белән юдырткан икән. Укытучы да шул ысулны кулланмакчы була. Үсмер каршы килми. Аның әти-әнисе дә укытучыга карата бернинди дәгъва белдермәгән. Әмма бу вакыйгадан соң директорга да, укытучыга да эштән китәргә туры килгән.

«Әти-әнисенең авызын юарга кирәк»

Укучыларыбызның фикерен белешү өчен, әлеге видеоязманы газетабызның «ВКонтакте»дагы сәхифәсенә дә урнаштырдык. Йөзләп кеше үз фикерен язып калдырган. Кайберләре үзләре дә мәктәп елларын искә төшергән.

«Кайчагында география укытучысы сыйныфтагы шкафка да яба, указка белән дә суга иде. Такта янында мисал чишкәндә, белмәсәк, математика укытучысы чеметкәннән беләкләр каралып чыга иде. Хәзерге укытучы шулай эшләсә, төрмәгә утыртып куячаклар. Укытучылардан зарланмыйм, яхшы белем бирделәр», – дип язган Рәйханә Ямалиева.

Алия Зарипова исә бу бәхәскә кушылып: «Хәзер әти-әни баласын Ходай урынына куя. Аңа үзе дә сүз әйтми, кешедән дә әйттертми. Укытучының бернинди хокукы юк. Аны тәмам хезмәт күрсәтүчегә әйләндереп бетерделәр. Минем дуслар укытучылыкка укып, икмәк пешерүче булып эшли хәзер», – дип язган. Тәнзилә Әхмәдиева мондый хәлнең килеп чыгуын әти-әнидән күрә. «Бөтен җаваплылыкны мәктәп өстенә аударалар. Карасын, имеш. Өйдә тиешле тәрбия алган бала мәктәптә килеп сүгенеп йөримени? Иң элек әти-әнисенең авызын кайнар су белән юарга кирәк», – дип, каты әйткән укучыбыз.

Директорлар нәрсә ди?

Сабын белән юып кына начар гадәт бетми, әлбәттә. Казандагы «Адымнар» күптелле белем бирү мәктәбе директоры, депутат Айдар Шәмсетдинов әнә шулай ди. Укытучының бу гамәлен дөрес дип санамый ул.

– Балалар үсмер вакытта сүгенү сүзләре куллана. Үзләренчә, кәттә буласылары килә. Шуңа күрә әхлак тәрбиясе кирәк, ә ул дини тәрбиядән башка була алмый. Татар балаларына мөмкин кадәр ислам мәгърифәтен аңлатырга кирәк, башка чара юк, – ди Айдар Шәмсетдинов. – Җәмгыятьтә халкыбызның әхлак дәрәҗәсе кимеде. Әгәр кешеләр бер-берсенә карата матур мөгамәләдә булса, балалар да шуннан үрнәк ала. Иң элек җәмгыятьтә үзгәрешләр булырга тиеш. Бездә укытучылар коридордан барганда, укучылар бервакытта да сүгенми. Укучыларны тыябыз, сүгенүнең никадәр ямьсез икәнен кат-кат аңлатабыз. Иң яхшысы – үгет-нәсыйхәт.

Башкаладагы балаларны олимпиадаларга әзерләүче махсус мәктәп («СОлНЦе») директоры Павел Шмаковтан да укучыларның сүгенүенә каршы нинди чаралар куллануын сораштык.

– Бөтенләй котылып булмый, әмма киметеп була. Бу – культураның бер өлеше. Кеше гаджетлардан башка яши алмый бит, сүгенү дә – тормышның бер кыйпылчыгы. Укучылар белән бу хакта линейкада сөйләшәбез, бер кыз фәнни эш язды хәтта. Бу уңайдан зур эш алып барабыз, – диде Павел Шмаков.

Оясында ни күрсә...

Берәү дә өендә баласын начар гамәлләр кылырга өйрәтеп утырмый, билгеле. Әмма бүген әтиләр генә түгел, әниләр дә сүгенә бит. Шулай булгач, алар баласына нинди кисәтү ясый алсын?! Ясаса да, баланың моңа исе китмәячәк. «Әтиең әйтәм», – дип куркытып та булмаячак. Кызганыч, бүген балалар бакчасына йөргән 4–5 яшьлек сабыйлар да ярамаган сүзләрне яхшы белә.

– Безнең өйдә мондый гадәт булмады. Әти беркайчан да ямьсез сүзләр кулланмады. Шуңа күрә сүгенгән кеше янында миңа бер дә рәхәт түгел. Тик менә оныклар кечкенә булса да, сүгенәләр шул. Өч малай да сүгенә. Ни өчен дигәндә, әтиләре ямьсез сүз ычкындырганнан сизми дә кала. Кияүне хурлыйсы килми, шәп ул безнең. Өйдә сүгенгәнне ишеткән бала ничек читтә калсын инде?! Интернеттан да тузга язмаган тапшырулар карыйлар. Балалар өчен мультфильм, тапшыруларны иләк аша үткәрергә кирәк, – ди Халисә Сираева.

Рафаэль Сәгъдиев – ике бала атасы, әти-әниләр комитеты әгъзасы. Үзе дә, балалары да сүгенү дигән нәрсәне белми икән.

– Безнең гаиләгә хас күренеш түгел бу. Мәктәптә укытучылардан зар ишеткән юк. Әти-әниләр белән аралашабыз. Сыйныфта берәр хәл булса, шундук төркемгә язалар. Укытучы уку өчен җавап бирә. Тәрбия – әти-әнидән, – ди Рафаэль. – Ишегалдында машина юлын каплап куйган өчен дә аты-юлы белән сүгенәләр бит хәзер. Бала тыңлап торып, барысын да истә калдыра. Әгәр минем рюкзакны кемдер тотып атса, мин дә шулай җавап бирә алам, дип уйлый ул. Бала юләр түгел, икенче вакытта әти-әнисенә: «Синнән ишеттем», – диячәк. Сүгенүне бары әти-әни генә туктата ала, минемчә.

Арча педагогика көллиятенең элеккеге директоры Илдус Сәгъдиев, баланы сугып, кыйнап акылга утыртып булмый, ди. Киресенчә, монда тәрбия эше кирәк. Ачуланудан файда юк.

– Мәктәпләрдә укытуга гына игътибар бирәләр. Укучылар, әти-әниләр белән тормыш, киләчәк турында бергәләп сөйләшү җитми. Элек сүгенгән балалар, эх, син малай актыгы, дип әйтүне бик авыр кабул итә иде, – ди Илдус Сәгъдиев. – Китап, матур әдәбият уку җитми бүген. Укымыйлар бит дип кенә калу дөрес түгел. Китап конференцияләре уздырып, балалардан үз фикерләрен әйттерергә кирәк. Китап, газеталар уку телне матурайта, чистарта. Язучылар берлегенең дә эше җитеп бетми. Элек язучылар мәктәпләргә очрашуга көтүе белән йөри иде. Хәзер сез язучыларның зур мәктәпләргә барып, өлкән сыйныф укучылары белән очрашуын ишеткәнегез бармы? Булса да, бик сирәк.

Фикер

Фирдүс ТЯМАЕВ, Татарстанның атказанган артисты:
– Бала сүгенгән өчен, аның авызына сабын тыкмыйлар. Беренчедән, ул аның баласы түгел. Барыбыз да хисләнеп сүгенәбез инде. Тормыш куабыз бит. Бу дөньяда сүгенмәүчеләр сирәк. Кемдер борын казый, кемдер колагын кашый – һәркемнең үз гадәте. Сүгенү белән дә шулай. Мин дә сүгенгәлим, хатыным Резидә: «Ник балалар янында сүгенәсең?» – ди. Олы улым килеп: «Әти, бу – начар сүз бит», – дип кисәтү ясый. Балалар янында үземне тыеп торырга тырышам хәзер. Хатын да, балалар да шулай тәрбияли мине. Котылып була, тик үзеңне җиңәргә кирәк. Барыбыз да матур сөйләшик! Тәмле телгә бернәрсә дә җитми.

Психолог киңәше

Наилә БӘШӘРОВА, Казандагы «Жасмин» үзәге психологы:
– Балалар үзеннән-үзе сүгенми. Гадәттә, алар моны башка кешедән – әти-әниләре, дусларыннан күрә. Әйтик, мәктәптә абруйлы булып саналган укучы сүгенсә, алар да шуны кабатлый, кәттә буласылары килә. Үсмерлек чорында күбрәк сүгенәләр. Бу – узып китә торган чор. Кисәтү ясап кына үзгәртеп булмый. Аңлатырга кирәк. Бер клиентым сөйләгән иде. Бервакыт аңа укытучысы: «Дамир, син бит – тәртипле бала, мин синнән моны көтмәгән идем», – дип кисәтү ясаган. Шуннан соң ул беркайчан да сүгенмәгән. Кисәтүне менә шулай итеп, кешенең шәхесен кимсетмичә ясау отышлы. Ачуланып кисәтсәң, күбрәк сүгенәчәкләр. Ярсыганга ярсып җавап бирергә ярамый. Һәр кешенең бер үзенчәлекле ягы була, менә шуны табып, хурлап түгел, киресенчә, күтәреп әйтеп куйсаң, тәэсир итмичә калмас.

Хокук

Булат ЗАКИРОВ, «Ватаным Татарстан» юристы:
– Закон буенча гражданнарга урамда сүгенү турыдан-туры тыелмаган. Ләкин берничә очракта урамда сүгенү җәмәгать тәртибен бозу дип саналырга мөмкин. Кеше сүгенеп, җәмәгать тәртибен бозса, РФнең Административ хокук бозулар кодексының (КоАП) 20.1 маддәсенең 1 өлеше буенча аңа 500 сумнан алып 1000 сумга кадәр штраф билгеләнергә мөмкин.
Полиция хезмәткәре сүгенү һәм тәртип бозуны туктатуны сораганда, аңа буйсынмасагыз, штраф суммасы 2,5 мең сумга җитәргә мөмкин. Шулай ук 15 тәүлеккә кадәр кулга алу да каралган.
Сүгенү сүзләре туганнарга яки башка таныш кешегә карата фатирда яки башка торак бинада әйтелгәндә, мондый сүгенү вак хулиганлыкка керми.
Кешене сүгенеп мыскыллаган чакта барыбер җавап тотарга туры киләчәк. Бу очракта 5.61 маддә буенча гражданнарга – 3 мең сумга, вазыйфаи затларга – 30 мең сумга кадәр, юридик затларга 100 мең сумга кадәр штраф салынырга мөмкин.

БАРЛЫК УЙЛАРЫМ ЮГАЛА...

ТЕЛЕФОН ДИП, ДӨНЬЯБЫЗНЫ ОНЫТМЫЙБЫЗМЫ?

Игътибар иткәнегез бармы икән: сез сөйләгәндә, әңгәмәдәшегез телефоныннан күзен дә алмый. Аның белән аралашу диварга борчак ату белән бер, диярсең. «Тыңлыйм, тыңлыйм, сөйлә», – дисә дә, уйлары һәм күзләре белән ул – телефонда. Галимнәр бу бәйлелекне фәнни телдә «фаббинг» дип атый. Шунысы да бар: әлеге күренеш кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләргә дә, сәламәтлеккә дә зыян сала, ди белгечләр. Ни өчен кеше бергә-бер аралашканда да, җансыз «иптәш»енә күбрәк игътибар бирә? Гомумән, кешелек, виртуаль дөньяга чумып, чынбарлыктан ваз кичмәдеме әле?

Илдар Мөхәммәтҗанов

Чишмә башы

Уйлап тапкан вакытта ук телефон, иң элек, кеше белән кеше арасын якынайту бурычын үтәгән иде. Бер рәхәтнең мең михнәте булган кебек, соңгы вакытта бик «акыллы»лана барган гаджетлар араларны ерагайта да башлады бугай.

«Фаббинг» дигән төшенчә «телефон» һәм «снаббинг» дигән сүзләрдән ясалган. Соңгысы – кешене хөрмәт итмәү, санга сукмау дигәнне аңлата. Шәхси аралашуга бөтен игътибарны бирер урынга, кешенең телефонга багынып утыруы дигән сүз инде бу. Хөрмәтсезлек дими, ни дияргә инде тагы?!

Телефон тоткан һәр кеше дә **фаббер** түгел инде анысы. Күпләр: «Миңа телефон эш өчен кирәк», – дияргә ашыгыр. Фабберны андыйлардан аера торган **билгеләр** бар.

☑Шәхси аралашу өчен бүлеп бирелгән вакытның күп өлешен смартфонда үткәрергә теләү.
☑Телефонның ашаган вакытта да, урамда йөргәндә дә, гомумән, теләсә нинди эш башкарганда да – янәшә, экран күренерлек рәвештә торуы.
☑Сезнең өчен телефон чыгарган һәр тавышның аңа карап алу өчен сигнал булып саналуы.
☑Нәрсәнедер белми калудан курку хисе булу.
☑Бер мәртәбә танышып чыккан мәгълүматны кабат-кабат карау.
☑Бер үк вакытта ике әңгәмә алып бару: чынбарлыкта һәм виртуаль.

Тикшерүләр ни ди?

Әлеге термин чит илләрдә инде 2012 еллардан бирле билгеле булса да, Россиядә яңа күренешләрдән санала. Хәер, бу күренешнең кайчан барлыкка килүе түгел, аның нәрсәгә китерүен белеп тору мөһимрәктер дә.

Әйтик, Техастагы Бейлор университеты галимнәре, фаббингның гаилә тормышына тәэсирен ачыклап, парлардан сораштыру үткәргән. Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, гаиләдә телефон аркасында ызгыш-талашлар еш чыккан. Кайбер очракта берәү гаилә эчендәге низагтан онлайн тормышка качарга тырышса, кайсылары өчен фаббинг үзе үк талашу сәбәпчесе булган.

Австралиядә дә шуңа охшаш сораштыру уздырганнар. Шул ачыкланган: фаббинг күбрәк яшь буынга хас. Ә моннан зыян күрүчеләрнең күп өлеше – хатын-кызлар һәм өлкән буын икән. Тагын да аяныслысы санда чагыла: сораштыруда катнашучыларның 62 проценты кеше белән сөйләшкәндә өстенлекне телефонга бирүләрен таныган.

Сүз уңаеннан, «ВТ» хәбәрчесе дә бу җәһәттән социаль челтәрдәге сәхифәсендә сораштыру үткәрде. Катнашучыларның 38 проценты, виртуаль дөнья дип, чынбарлыкны онытмый. Ә калган 59 проценты үзләрен телефонга бәйле дип саный икән. Тагын 3 проценты чама хисен саклавын белдерде.

Чиксез читлек

Ни сәбәпле чынбарлыкны виртуаль дөньяга алмаштыру ягын карыйбыз соң? Чынбарлык та бит кызыксыз түгел. Әмма күзләр дә, куллар да гел җансыз «дус»ка тартыла.

Психология фәннәре докторы, мөгаллим Ольга Дейнека фикеренчә, кешеләрнең онлайн мохиткә тартылуы ихтыяҗларын канәгатьләндерү теләгеннән килә.

– Кешеләр онлайн мохиттә күңел ачу һәм үз ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен вакытын җәлләми: алар онлайн сатып алулар башкара, аралашу өчен кеше эзли, онлайн уеннар уйный. Заманча социализация процессы цифрлы мохиткә бик тә бәйле. Шунысы да бар: социаль борчылу дәрәҗәсе югары булган кешеләрнең смартфонга бәйлелеге зуррак, – ди белгеч.

Блогер Ренат Галиәхмәтов үзенең фаббинг тарафдары булуын яшерми. Дөрес, элегрәк вакытта. Телефонга бәйлелек психик авыру дәрәҗәсенә җитәрлек булган хәтта.

> **САН**
>
>
>
> Тикшерүләр күрсәткәнчә, ресторанда бер кичке аш вакытында якынча 36 фаббинг очрагына юлыгырга мөмкин.
> Үсмерләрнең 87 проценты күзгә-күз карап түгел, гаджет аша сөйләшү яклы.
> Кешеләрнең 97 проценты телефон тотып ашаган вакытта ризыкның тәмсезрәк булуын әйтә.

– Хәзер мондый нәрсә белән чирләмим. Мин моның чир икәнен чынлап та аңладым һәм бетерү өчен тырыштым. Әйтик, элек иртән торуга, телефонга ябыша идем. Әйе, хәзер дә кулга алам. Әмма максатсыз түгел инде. Әйтик, файдалы, эчтәлекле мәгълүмат белән танышу өчен, – ди блогер. – Әти-әниләр янына кунакка кайткач, алдан ук фото-видео төшерәм дә телефонны читкә алып куям. Аралашуга күбрәк вакыт калсын, дим. Бала тууга да зур йогынты ясагандыр, дип уйлыйм. Аның белән күбрәк вакыт уздыру теләге барлыкка килде. Машинада барганда да телефонда утырырга тырышмыйм инде хәзер.

Табиб-психиатр Александр Мещеряков гаджетларга бәйлелекнең сәбәпләрен аңлатты. «Бердән, үзеңә һәм башкаларга кирәк булырга омтылу. Икенчедән, ялгызлыктан курку. Өченче сәбәп – чынбарлыкта элемтәләр корудан курку. Мәсәлән, «котлыйм сине» дип тел белән әйткәнче, коры хат-хәбәр язу күпкә җиңелрәк бит. Бәйлелектән котылуның кызык бер ысулы бар. Әйтик, велосипедта барганда, йөгергәндә, бакча казыганда – гомумән, кулымле эш башкарганда телефон тотып булмый бит. Димәк, дәвасы – физик эш һәм активлык», – ди белгеч.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Котылу юлы бармы?

Фаббинг – кешедә яши-яши барлыкка килә торган гадәт ул. Алдарак искәрттек инде: аны проблема буларак та күптән түгел генә карый башладылар. Гадәт булгач, аннан котылып та була, димәк. Әйе, котылу вакыт таләп итәчәк, ләкин психик сәламәтлек һәм кешеләр белән мөнәсәбәтләр тәртиптә булсын өчен кирәк ул.

✷**Телефонсыз почмак.** Үзегез өчен шундый кагыйдә булдырыгыз: ашаганда беркайчан да, нинди генә хәл булса да телефоны кулга алмаска, янәшә куймаска. Бигрәк тә кем беләндер ашаганда.

✷**Югалтабыз.** Телефоныгыз барлыгын онытыгыз. Әлбәттә, баштарак кул-аяксыз калгандай булырсыз. «Берәр җирдә төшереп калдырдым микән әллә?» дигән шикләр дә туар. Әмма ияләшерсез. Киресенчә, берничә сәгатькә телефонны берәр букчагызга йә киштәгә салып кую хәерлерәк тә булыр. Кайчагында югалтуларның да файдага булуын аңларсыз. Ул арада вакытны башкача үткәрергә мөмкин.

✷**Уйный-уйный онытабыз.** Үзегезне сынап карагыз: ничә сәгать телефонсыз тора аласыз икән? Әйтик, билгеле бер вакыт узганнан соң, ихтыяр көчегез нык булган өчен үзегезгә кечкенә бүләк тә ясый аласыз.

✷**Игътибарны арттырабыз.** Медитация ише тынычлану һәм игътибарны арттыру кебек ысулларны көндәлектә куллана башлагыз. Алар да булышмаса, психолог, терапевт кебек белгечләр белән аралашу зыян итмәс. Күпчелек бит, чынбарлыктан качам һәм ял итәм дип, смартфон белән мавыга башлый. Бу исә депрессиягә кадәр барып җитәргә мөмкин.

Башкаларга ничек булышырга?

✷**Үрнәк булыгыз!** Сезнең якыннарыгыз арасында фаббер бар икән, аны телефон колы булудан коткару өчен, шәхси үрнәк күрсәтә аласыз. Әйтик, очрашкач, аңа күрсәтеп, телефонны читкә алып куегыз.

✷**Турысын әйтегез.** Кеше үзенең хаталануын сизмәскә дә мөмкин бит. Шуңа да фабберга аның ни эшләгәнен турыдан әйтергә кирәк. Моның проблема икәнен аңлатырга да була. Әмма аны гаепләмәгез, тавыш күтәрмәгез! Тыныч кына үз кичерешләрегезне аңлатыгыз, ул телефонга текәлеп утырганда, үзегезне ничек хис итүегезне сөйләгез. Шундый сүзләрдән соң кеше уйга калырга тиеш.

✷**Чамасын белеп кенә.** Берничә кеше бергә очрашкан вакытта, алдан ук кисәтеп куярга мөмкин. Мәсәлән, аралашу вакытында телефоннары куеп торыгыз һәм соңыннан гаджетларга биш минут вакыт бүлеп бирегез. Бу вакыт арасында очрашуга җыелучылар хат-хәбәрләрне тикшереп алырга, шалтыратырга өлгерәчәк. Мөнәсәбәтләргә дә зыян килмәячәк.

✷**Кем карый – шул түли.** Әйтик, сез кафе-ресторанда дуслар белән очрашыгыз, ди. Җанлы очрашуны «җансыз» телефоннар бозмасын өчен, алдан ук килешеп куегыз: кем телефонына текәлеп утыра – шул кафе-ресторанда ашап-эчү өчен түли. Нинди генә юмарт булса да, кешенең артык акчасы булмый ул.

МӘХМҮТ ГАЛӘҮНЕҢ ОНЫГЫ АНАСТАСИЯ:

«БАБАЙ 85 ЕЛДАН СОҢ РУХИ ЯКТАН АКЛАНДЫ»

Мәхмүт Галәү шәхесе хәтердә Камал театры премьерасыннан соң кабат яңарды. Аның оныгы спектакльнең язучы атып үтерелгән көнне, 4 ноябрьдә чыгуына игътибар иткән. Әлеге фаҗигадән соң 85 ел үткәч. Аның әйтүенчә, Мәхмүт Галәүгә бәйле очраклыклар шактый.

Анастасия ГАЛӘВЕТДИНОВА белән тарихтагы ак таплар, язучы шәхесенә бәйле хаталар, әдәби әсәрләренең, нәселенең язмышы хакында сөйләштек.

:: Анастасия, язучы оныгы булуыгызны кайчан белдегез?

– Мин аны һәрвакыт белдем, әмма тулаем аңлау һәм шушы нәселнең варисы булу җаваплылыгы еллар узганнан соң гына килде. Бер вакыйганы искә алып үтим әле. 2016 елның августында үз эшләрем белән Казанга килдем. Шунда иптәш кызым белән экскурсовод алып Казан буйлап сәфәр кылдык. Нәкъ менә шунда беренче тапкыр безнең гаиләгә карата кызыксыну тойдым. Мәрҗани мәчете тирәсендә: «Мин Шиһабетдин Мәрҗани нәселеннән, Мәхмүт Галәүнең оныгы булам», – дигәч, экскурсовод та кызыксынып китте. Шуннан язучы бабамның шәхесе Татарстанга кызыклы дигән нәтиҗә ясадым. Экскурсовод исә: «Шундый нәсел кешесе булгач, нишләп үзегез турында әлегәчә белгертмәдегез?» – дип сорады. Әмма әтидә андый максат булмады. Хәер, ул омтылып карады, әмма җавап ала алмады. Миңа калса, вакыты җитмәгән булган. Әле дә истә: Тукай музеенда ремонт иде. Бинаны әйләнеп чыктым да, төзүчеләрдән: «Хәзер музей кайда урнашкан соң?» – дип сорадым. Төзүчеләр миңа музей директоры Гүзәл Төхвәтованың телефонын бирде. Мин элемтәгә чыктым, ул шунда ук очрашуга чакырды. Бу очрашу Милли музейда узды. Нәкъ менә шушы очрашу вакытында без шул ук елны, ноябрь аенда Мәхмүт Галәүнең 130 еллыгын билгеләп үтәргә дип килештек. Әти белән әлеге чарада катнаштык. Мәхмүт Галәүнең истәлекле медальләрен әзерләдек һәм аны язучы мирасын саклау һәм яктырту эшендә катнашкан шәхесләргә тапшырдык. Сүз уңаеннан, әлеге медаль Минтимер Шәймиевтә дә бар. Беренче Президент Мәхмүт Галәү иҗаты белән таныш булуын, аның китапларын берничә тапкыр укуын сөйләде һәм безгә аның шәхесен танытуда ярдәм итәчәген әйткән иде. Ул шулай булды да. Аның ярдәме белән Арчаның Ташкичү авылында Мәрҗани, Галәү һәйкәлләре ачылды.

:: Нәселегездә әдәбиятка якын һөнәр сайлаучы булдымы?

– Безнең гаиләдә бер генә кеше дә гуманитар юлдан китмәгән. Әнием Мария Александровна гына белеме буенча – филолог, рус теле һәм әдәбияты укытучысы. Ләкин ул Мәхмүт Галәү варисы түгел. Әмма нәкъ менә ул язучы иҗаты белән кызыксынуны, эзләнүне уятып җибәрде. Мин – табиб, апам – бизнес өлкәсендә, әтием – инженер, бабам – Мәхмүт Галәүнең улы Надир – хәрби. Күргәнегезчә, барыбыз да әдәбияттан ерак торабыз.

:: «Мин һәрвакыт язучы оныгы булуымны белдем», – дидегез. Гаиләгездә Мәхмүт Галәү турында сөйләшә идегезме?

– Мәхмүт Галәү архивының безнең гаиләгә килеп эләгүе – үзе бер маҗара. Аны аңлату өчен, мөгаен, язучының биографиясен искә алырга кирәктер. Моннан тыш, безнең өйдә аның китабы бар иде. Татар телендә булганлыктан, аны мин укый алмадым. Хәер, рус телендә булса да, бала вакытта аны укый алмаган булыр идем. Килешәсездер, бик авыр роман. Әмма безгә бабагызның әтисе бик зур язучы булган дигәнне бәләкәй чактан сеңдереп килделәр. Ә архивның барлыгы турында соңрак белдем. Аны безгә почта аша Хабаровскига язучының өченче хатыны варислары җибәргән иде. Инде бабам Надир турында берничә сүз. Ул – хәрби, шуңа күрә без шәһәрдән шәһәргә күченеп йөргәнбез. Югары белемле, Ленинград хәрби академиясен кызыл дипломга тәмамлаган, диплом эшен немец телендә яклаган. Берничә тел белгән, әмма без аңардан беркайчан да татарча сүз ишетмәдек. Хәтта «исәнмесез» дип тә әйтмәде ул. Әмма бабай өйдә түбәтәй кия, авыл гадәтләре дә калган иде. Әтисен – Мәхмүт Галәүне кулга алганда аңа 14 яшь булган. Без хәзер, мөгаен, система аның элеккеге никахларыннан булган балаларын эзәрлекләмәгәндер, дип фаразлыйбыз. Шулай да әтисе кулга алынгач, Надир бабайны Башкортстандагы туганнарында качырып тотулары билгеле. Балалар язмышына күбрәк тукталсак, хәлләр болайрак. Мәхмүт Галәү өч тапкыр өйләнгән. Беренче хатыны Хәдичәдән Диләрә исемле кызлары туа. Диләрәдән киткән оныклар – рус телләләр. Мин эзләп тапкан туган хәзерге вакытта Америкада яши. Икенче хатыны – Фатыйма Сабитова, аннан уллары Надир туа. Бу инде – безнең гаилә. Надирның улы

Олегтан без – апам белән мин туганбыз. Язучының өченче хатыны – Зәйнәп Хәсәнова. Аннан аларның кызлары Ләлә туа. Мәхмүт Галәүнең фаҗигасе бу хатынны да урап узмый. Аны кулга алып, Караганда өлкәсендәге Карлаг хезмәт белән төзәтү лагерена җибәрәләр. Сигез елдан соң аны вакытыннан алда шартлы рәвештә азат итәләр. Кызы Ләләне исә, әнисеннән аерып, Иркутскидагы балалар йортына озаталар. Монда Ләлә Лидиягә әверелә. Ул чакта Ләләгә чама белән сигез яшь була. Гаилә архивында шушы балалар йорты тәрбиячесенең Зәйнәп апага 1939 елның декабрендә язган хаты саклана. Безнең өчен кадерле ядкәрләрнең берсе ул. Анага бу хатның никадәр кадерле, никадәр әһәмиятле булуын аңласагыз иде. Аңа бит баласының исән-сау булуын һәм кайда яшәвен хәбәр иткәннәр! Хат мәгълүматка бик бай. Җәй аенда кызның 90 китап укуы, белем алудагы уңышлары өчен күлмәклек тукыма белән бүләкләнүе дә әйтелә. Шөкер, Зәйнәп иреккә чыккач, кызын үзенә кайтара ала. Алай гына да түгел, Зәйнәп безнең бабай Надир белән дә аралаша, аларның ике арада йөргән хатлары да – кадерле ядкәр. Диләрә дә әлеге аралашуга кушылып китә. Өч никахтан туган балалар бер-берсен табышалар. Мәхмүт Галәү архивын исә шушы Зәйнәп апа туплый һәм аны соңрак безгә посылка белән җибәрәләр.

:: Мәхмүт Галәү – Шиһабетдин Мәрҗанинең туганы. Сез Мәрҗаниләр нәселе белән аралашасызмы?

– Мәрҗанинең ун туганы булган. Аның берсе – Галәветдин. Без Галәветдин нәселенә карыйбыз. Калган тармаклардан да варислар шактый. Сүз уңаеннан, миндә Мәрҗаниләрнең шәҗәрәсе саклана. Моны инде хәзер рәсми төстә игълан итсәң дә буладыр. Ул вакыйга болай булды. Миңа татар халкы генеалогиясен өйрәнүче галим Гадел Бакый улы Беляев белән очрашырга насыйп булды. Ник дигәндә, аның китабында Мәрҗаниләр нәселе урын алган, тик бу нәселдә безнең гаилә күрсәтелмәгән иде. Мәхмүт Галәү тармагында кызы Диләрә аның сеңлесе итеп күрсәтелгән иде. Шул хатаны төзәтергә кирәк дип, 85 яшьлек галимне эзләп таптым. Ул китаптагы хатаны кулдан төзәтте һәм, сез минем бу китапны яңадан чыгарырга вакытым калмаганны аңлыйсыз инде дип, Мәрҗанинең кульязма хәлендәге шәҗәрәсен миңа тапшырды. Менә шунда мин җаваплылыкның никадәр авыр йөк булуын тойдым.

:: Сездә сакланган архивта әдәби әсәрләр яки язучы истәлекләре бармы?

– Кызганыч, кулга алынганда әдәби әсәрләрне дә алып китәләр. Бездә исә кулга алынучының шәхси эше күчермәсе саклана. Аны әти-әниләр соравы буенча 2009 елда Лубянкадан Хабаровскига юлладылар. Гаилә архивының ничек туплануы турында да сөйләп үтәсем килә. Без аның өчен Мәхмүт Галәүнең өченче хатыны Зәйнәп апага бик рәхмәтле. Чөнки ул, иреккә чыгып, үзенә куыш тапкач, иренең исемен аклау эшен башлап җибәрә. 1956 елда Мәхмүт Галәү хаксызга хөкем ителде дигән шикаять яза. Шуннан соң Югары суд язучының үлгәннән соң исемен аклаган карар чыгара. Зәйнәп менә шушы зур эшне башкарып чыга. Сүз уңаеннан, Зәйнәп апа 1969 елда Мәскәүдә вафат була. Мин күпме генә эзләсәм дә, мөселман зиратында аның кабе-

Военная Коллегия
Верховного Суда
Союза ССР
14 марта 1957
№ 4н-018171/56
Москва, ул. Воровского, д. 13.

СПРАВКА

Дело по обвинению ГАЛЯУТДИНОВА Махмуда Галяутдиновича пересмотрено Военной коллегией Верховного Суда СССР 9 марта 1957 года.

Приговор Военной коллегии Верховного Суда СССР от 4 ноября 1937 года в отношении ГАЛЯУТДИНОВА М.Г. по вновь открывшимся обстоятельствам отменен и дело прекращено за отсутствием состава преступления.

ГАЛЯУТДИНОВ М.Г. реабилитирован посмертно.

ПРЕДСЕДАТЕЛЬСТВУЮЩИЙ СУДЕБНОГО СОСТАВА
ВОЕННОЙ КОЛЛЕГИИ ВЕРХОВНОГО СУДА СССР
ПОЛКОВНИК ЮСТИЦИИ
/КОСТРОМИН/

рен таба алмадым әле. Әмма өметне өзмәдем. Мөгаен, бер төркем туплап, эзләргә керәктер. Зәйнәп апа вафатыннан соң Мәхмүт Галәүгә кагылышлы барлык документлар кызы Ләлә кулында кала. Ул 1982 елда вафат була. Аның ире Иван, Ләләнең үлеменнән соң туган якларына, Белоруссия дип истә калган, китеп бара. Күрәсезме, бер гаилә тарихында гына да кешеләрнең ничек тулгануын, язмышларның ничек чуалуын күреп була. 30–40 нчы еллар эше бит инде бу. Үлеме алдыннан Иван Мәхмүт Галәү мирасын Надир гаиләсенә тапшырырга дип васыять әйтеп калдыра. Аңа бу гамәле өчен бик зур рәхмәт. Юкса бит хатынының кәгазьләрен сакламаса да, гаеп итеп булмас иде. Шулай итеп, туксанынчы еллардан башлап Зәйнәп апа архивы бездә.

Әмма ул нигә еллар тик ятты. Әйтәм бит, без – әдәбияттан ерак кешеләр. Әберенче омтылышны әлегә дә баягы әни ясады. Аның тәкъдиме белән 2001 елда әти Казандагы әдәби музейга шалтырата, үзенең Мәхмүт Галәү оныгы булуын хәбәр итә. Әмма аның белән кызыксынмыйлар. Мин моны гаепләп әйтмим, вакыты җитмәгән булгандыр. Аннан 2009 елда тагын бер омтылыш була. Тагын берниндн җавап юк. Шушы елда әти белән әни «Мемориал» җәмгыятенә бара һәм аларга Үзәк архив белән ничек эшләргә кирәклеген аңлаталар. Шулай итеп без Лубянкадан архив күчермәләрен һәм Мәхмүт Галәүнең төрмәдә төшерелгән фотосын ала алдык. Ә бит ул фотога күз яшьләрсез карап та булмый. Бабам үзен менә-менә атып үтерәчәкләрен аңлаган, аның бөтен өмете өзелгән. Фотоны кулына алгач, нинди кырыс әти дә елаган иде.

> Мәхмүт Галәү эшенең кайбер битләрен күрсәтмәделәр. Алар дәүләт сере булып санала. Анда нәрсә барлыгын без 100 ел үткәч, ягъни тагын 15 елдан соң гына белә алачакбыз. Мөгаен, анда донос язучыларның исемнәре булгандыр. Сүз уңаеннан, без бу фотоны, кайбер документларны, бабаның шәхси әйберләрен музейга тапшырдык.

:: 4 кисәктән торган «Канлы тамгалар» эпопеясыннан да бары икесе – «Болганчык еллар» белән «Мөһаҗирләр» генә безнең көннәргә, алары да тәрҗемә хәлендә килеп ирешкән. Сез Мәхмүт Галәүнең әдәби мирасы кайдадыр саклана дип уйлыйсызмы? Аларны кайчандыр табуга өметегез бармы?

– Мин алар кайсыдыр архивларда саклана дип ышанам. Әмма Үзәк архивтан бу җәһәттән уңай җавап алмадык. Миңа алар кайчандыр килеп чыгар төсле. Әлегә гаилә архивын бастырып, дөньяга чыгару турында уйланам. Галәү – минем өчен гади генә фамилия түгел. Ул – бик зур җаваплылык. Гәрчә миндә татар каны гына акмаса да. Гәрчә шундый нәсел кешесе булу җаваплылыгы еллар узгач кына килсә дә. Димәк, татар каны барыбер көчлерәк.

:: Сезнеңчә, Мәхмүт Галәүгә караш җылындымы инде?

– Әлбәттә. Мин аның рухының тынычлануын телим. Татарстандагы язучыга карата кызыксыну, аның үлгән көнендә, 4 ноябрьдә Камал театрында «Болганчык еллар. Мөһаҗирләр» спектакленең куелуын мин язучыны рухи аклау дип кабул итәм. 1957 елның 9 мартында документаль рәвештә акланса, хәзер рухи яктан. Нәкъ 85 ел узганнан соң. Бу махсус эшләнгән эш тә түгел. Димәк, вакыты җиткән. Сезнең белән исә бабайның тууына 136 ел тулырга бер көн кала, 7 ноябрьдә сөйләшәбез менә. Болар барысы да өмет уята.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ЛАНДЫШ ӘБҮДӘРОВА

УМАРТА

(ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК)

< Дәвамы. Башы 14, 21, 28 октябрь, 4 ноябрь саннарында

Камилнең осталыгы көннән-көн арта иде. Остарган саен, гипотезасында шикләре дә күбәя. Нәфисәнең сере башкада кебек тоела аңа, гипнозга бәйле түгел бугай. Шуңа да үзенең уй-фикерләрен берәрсе белән бүлешәсе килә иде. Илнурга әйтеп караса? Ул да, галим булам, Нәфисәгә шулай ярдәм итәм, ди бит. Ярминкә көн иде. Камил төрле хайваннар карарга дип иртән иртүк ярминкәгә чыкты. Үз ишләре шактый иде ярминкә мәйданында. Араларында Илнур да бар. Камил озакка сузып йөрүнең мәгънәсен күрми иде, шуңа да Илнурны читкәрәк чакырып алып, серен чиште.

– Кит аннан! Чынмы? – диде Илнур, шаккатып.

– Валлаһи, теләсә нинди хайванны гипнозлый алам.

– Кешеләрне дәме?

– Кемне? Синең белән беренче бүлешәм. Кайчак дәрестә тарих укытучысы Мәхмүт абыйны йоклатыштырган бар. Әмма белеп булмый: ул болай да аяк өсте йоклап йөри торган кеше. Ышанычлырак кеше кирәк.

– Әйдә, күрсәт әле, болай гына ышана торган нәрсә түгел бу. Нишләп үземнең башка килмәгән? – дип, Илнур Камилдән хәзер үк гипнозлап күрсәтүен сорады. Аның көтеп торасы килми иде.

Камил белән Илнур рәт аралары буйлап китте. Күрше авылдан кызыл-җирән яулыклы, йомры битле мари апасы тере тавыклар сатарга алып килгән. Тавыклары да үзе кебек җирән-кызыл иде.

– Апа, тавыкларың әйбәтме? Карт түгелме? – дип сорады Камил, чын хуҗалыкчыл ирләрчә кызыксыну белдереп.

– Әйбәт булмаган кая! Күкәйне коеп кына торалар. Ышанмасаң, тотып кара! – дип сүзгә саранланмыйча, татарчасын марича көйгә җырлап бирде кызыл яулыклы апа.

Үсмер егетләргә шул сүз генә кирәк иде, Камил җитез генә бер тавыкны алды да, сатучы апа икенче тавыгын алырга кәрҗиненә иелгән арада, гипнозлап салды.

– Нишләттең? – дип яшелле-кызыллы тавыш белән кычкырып җибәрде яшелле-кызыллы яулык бәйләгән йомры апа, балавыз кебек сузылып төшкән тавыгын күреп. – Карагыз, тавыгымны харап итте, тотыгыз! – дип такмакларга тотынды шунда ук. Камил белән Илнурга тиз арада табан ялтыратырга кирәк иде. Алар икесе ике якка атылды. Мари апасы әтәч-тавыкларын онытып, ду килеп малайларны куа китте. Ул арада «үлгән» дигән тавыгы сикереп торды, кәрҗиндәгеләре дә иркен дөньядан чикләп торган япма юклыгын күреп, җиргә сикереп төштеләр дә нәкъ кешеләр кебек, кайсы якка карап чабарга икәнен дә белмичә, төрле якка чәчелделәр. Әтәч белән Миңнегали карт кына бу шаукымга иярмәде. Әтәч койма башына сикереп менде дә бертуктаусыз кычкырырга тотынды, Миңнегали карт исә кайда торган булса, шунда басып, берәр нәрсә күздән ычкынмасын тагын дигәндәй, ялт-йолт килеп, дикъкать белән күзәтә башлады. Ике малай рәт араларыннан елгыр гына, берәүгә дә тоттырмыйча сикергәләп үттеләр дә кырыйдагы куаклыкка кереп чумдылар. Мари апасы Зоя болай гына тынычлана торганнардан түгел иде, шуңа да ул малайларны тота алмагач, Илнурның әнисе Фатыйманы танып, аны җиңеннән эләктереп алды да сөйрәп диярлек кәрҗиннәре янына алып китте. «Үлгән» тавыгын әни кешенең борын төбендә селкетә-селкетә, улын эт итеп сүгәргә теле кычытып тора иде. Чандыр, җыйнак гәүдәле Фатыйма тетя Зояның кулыннан бигрәк аның теленә эләгүдән курка иде: апакай аны да гадәтенчә оят сүзләрнең барысын берьюлы бер җөмләгә сыйдырып мыскылласа, ничекләр күтәрер? Кып-кызыл итеп буяган олы авызын ачкан җирдән ябарга да онытып туктап калды Зоя апакай. Хәтта Фатыйма да Зояның ныклы кулларыннан ычкынырга теләп, өстерәлеп барган җиреннән, киресенчә, аңа ныклап ябышты.

Тавыклар бер җепкә тезгән кебек ниндидер бер көчкә буйсынып, җидесе бергә әтәч артыннан бардылар да каз оясы кебек киң авызлы кәрҗингә берәм-берәм сикереп менеп утырдылар. Иң соңыннан әтәч кунаклады. Зоя Фатыйма турында шундук онытты, соңгы биш минут эчендә булган хәлләр аны чын-чынлап кыен хәлгә куйган иде.

– Кара әле, Зоечка, – диде телгә килеп, кет-кет кеткелдәп Миңнегали карт. – Синең тавыкларың да үзең кебек артист икән...

Күрше мари авылында яшәүче Зояны тирә-якта белмәгән кеше юк, олырак ирләр аның яшь чагындагы «әтчәйний» чагын хәтерләп, Зоечка гына дип йөртә иде.

– Авылыгыз белән бертөрле икәнсез, – диде ул тиз-тиз генә кәрҗиннәрен җыйнаштырып. – Җенле-пәриле. – Шулай диде дә туп-туры Фатыйманың күзләренә карады. Тегесен калтырау алды. Кызы туганнан бирле капканың бу ягында сирәк күренә торган Фатыйма кирәкяракка дип, тиз генә базарга чыгып кермәкче иде, көтмәгәндә игътибар үзәгенә әйләнде дә куйды. Колак очларына кадәр кызарганын сизде ул: бу минутларда Зоя түткәй генә түгел, авылдашлары да аны җенле дип уйлагандай тоелды. Ул кешеләргә күзләрен күтәреп карарга да кыймыйча, кайту ягына йөгерде.

Бу хәлләрнең шаһиты булган Энҗебикә дә базар көн ярминкәсенә алып чыккан каймак-эремчеген сатып тормыйча, тизрәк өенә ашыкты. Улын күрергә кирәк иде аңа.

– Синең хикмәтме? – диде ул өйгә керә-керешкә. Улының өйгә кайтып, аны көтеп утыруына тамчы да шиге юк иде аның.

– Юк, әни, ул үзе... – диде Камил.

– Синең ул китапларыңны тапмаган дип беләсеңме әллә? Әллә кайчан мичкә яктым инде мин аларны, – дип ысылдады әнисе. – Бохарны да син генә боздың, – дип тушәм ярыгына кыстырган сыек чыбыкка үрелде.

Энҗебикәнең чыбыкка үрелү мизгелен Камил дә, Бохар да бик яхшы сиземмли. Шуңа да үсмер әнисеннән өлгеррәк булып чыкты, сыек чыбык эләккәнче, алар Бохар белән чыгып йөгерде.

– Мин ул китапларны яттан беләм! – дип кычкырды ул әнисенә ишек аша. Урамга чыгуга, Илнурны эзләп табарга кирәк, дип тапты.

Ул көнне имән төбендә Илнурны гипнозлап йоклатып карады ул.

Тәҗрибә уңышлы чыкты, ләкин Камилгә осталыгын арттыру өчен Илнур гына җитми иде. Дөресрәге, гипнозлап йоклатып җибәрү вакытын күз ачып йомган арага гына калдырасы бар иде. Чөнки Нәфисәне күрүгә, Камил алданрак гипнозлап өлгерсә, сер чишеләчәк иде, ягъни кызга тумыштан гипнозлау сәләте бирелгән дигән гипотеза расланачак иде. Хәер, вакыт бар әле: Нәфисә ата йортында яши, бакча артындагы аңа дигән мәһабәт сарай яртылаш кына төзелгән. Аның каравы кызчыкны ике абыйсы укырга-язарга, санарга өйрәтә, китаплар укыйлар. Мостафалар турыннан кичкә таба үткән кеше аларда һәрвакыт моңлы итеп җырлаган тавыш ишетә. Төскә-биткә генә гүзәл түгел балакай, тавышы да үзәкләреңне өзәрлек итеп чыга иде аның. Өстәвенә абыйлары өйрәткән һәр сабакны тиз арада отып ала торган үтә дә сәләтле бала булып чыкты.

Яшь гипнотизёр иптәш табылуына сөенеп туя алмады. Илнур өзми дә куймый «мине дә өйрәт» дигәч, аны шәкерте итеп гипноз серләренә төшендерә башлады. Тиз өйрәнде тегесе. Авыл халкы Илнур белән Камилне һәм алардан бер адым да калмаучы Бохар мәчесен гел бергә күрергә тәмам ияләшеп бетте. Укуда да, эштә дә, спортта да алдынгы егетләр, маңгайларына булачак галимнәр дә, булачак чемпионнар да дип, бердәй тигез язылган. Тик бу үсмерләрнең башкалар белән әллә ни аралашмыйча, үзаллы йөрүләре, күбрәк хайван, кош-корт тирәсендә мәш килүләре генә сәерсендерә иде. Гадәттәгечә, Зарифә белән Миңнегали картның очлы күзе мондый вакытта тагын да уяурак күрә башлый.

Бервакыт теге өчәү – Илнур, Камил һәм Бохар мәчесе имән төбендә мәртәкә киткәндәй бер ноктага төбәлеп катып утырганда, яннарына Миңнегали карт килеп чыкты. Малайларның болай утыруы бер хәл әле, мәчесенә ни булган диген? Арт тәпиләрендә кымшанмыйча да басып тора бит! Телсез калды Миңнегали карт.

– Ыһым-ыһым, – диде ул, үзенең барлыгын сиздереп, күзләренең дөрес күрүенә инангач. Тегеләр чыннан да сискәнеп киттеләр, алар октябрь ахырында кичке эңгер-меңгердә юкәлектә кеше йөрер дип уйламаганнар да иде.

– Әәә, Миңнегали бабай, исәнме? – диделәр егетләр, сикереп торып. Бохар агач башына менеп качты.

– Нишләп утыруыгыз булды бу, оланнар? Иманыгызга оедыгызмы? Әнкәләрегез беләме монда икәнегезне?

Егетләр дәшмәде. Әлбәттә, белми, белмәскә дә тиеш әле. Ә Миңнегали карт күргәч, әнкәләре генә түгел, иртәгә таңга кадәр бөтен авыл радиодан тыңлагандай булачак. Шуңа да алар бер-берсенә карашты да ым кагышты.

– Белә-белә, Миңнегали бабай, – диде алар һәм Камил әкрен генә килеп, Миңнегали картка кулын сузды. Карт буыннары йомшарып киткәнен генә тойды, калганын хәтерләми. Каравыл йортында аны төнгә эшкә килгән Зарифә уятты.

– Пост сдал, пост принял, – дип шаяртты ул Миңнегали картны. – Нишләп соңга калдың? Өйдәгеләр югалтыр бит үзеңне!

– Урап кайтыйм әле дип чыккан идем... Аякларны ял иттереп алыйм, дип утырган идем... Картлык бит... – Миңнегали карт чыннан да берни дә хәтерләми иде. Бары тик берничә көннән соң теге ике үсмергә ияргән Бохарны күргәч кенә күңел төбендә ниндидер бер хис хәтере кымшанып куйгандай булды, ләкин ул да искә төшкәнче онытылды. Миңнегали карт кичәгене түгел, ә моннан кырык-илле ел элек булганнарны яхшырак хәтерләр яшькә җиткән кеше иде инде.

Дәвамы бар >

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1. **ЯЗЫЛ!** 2023 елның беренче яртыеллыгына **«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»** газетасына язылу

2. **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3. **БҮЛӘККӘ**
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435 жомга саны
512 сум 70 тиен

П2409 атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама



Әз-мәз мәзәк

– Матурым, сиңа минем яңа прическам ошыймы?
– Борчылма, чәч тагын үсә ул.

* * *

– Авырып киттеңме әллә?
– Юк.
– Ә ник дару эчәсең?
– Чөнки иртәгә срогы чыга.

* * *

Безнең эрага кадәр яшәүчеләр еллар санының кимеп баруын ничек аңлатканнар икән?

* * *

Зоокибеттә:
– Ә бу балыгыгыз күпме тора?
– Ул сатылмый.
– Ник?
– Тота алмыйбыз.

* * *

– Хатын-кызны көлкегә калдырырга яратучы кешене ничек дип атыйлар?
– Кутюрье.

«Чувак»лар сүзлеге

- **Кринж** – оят хәл
- **Рофл** – көлкеле хәл
- **Рили** – чынлап
- **Фейл** – хаталану
- **Кейс** – мисал, очрак
- **Юзер** – кулланучы
- **Лузер** – хәчтерүш
- **Факап** – уңышсызлык
- **Рандом** – очраклылык
- **Дешманский** – хәерче
- **Скилл** – һәвәслек
- **Изи** – җиңел, ансат
- **Харэ** – җитте



Сканворд җаваплары

Горизонталь: Башкортстан, Руис, ипсез, риал, Сыркыды, Ив, атка, ут, архив, ура, ай, агыла, Зозуля, ал, затлы, хан, эх, кыска, Ык, азу, Айрат, аң, Илдар, Сәхнә, как, икебана, Барлас.

Вертикаль: ураза, Камал, алпавыт, Йолдыз, СКА, суер, куен, кузак, хәл, Ла, Агутин, аять, Ләис, тары, Ира, ашыгыч, Ален, трактор, аулык, Хуанхэ, кач, ни, Данир, ахырзаман, Ватан, каз.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Беләсең килсә...

1 Татарстанның халык рәссамы Әхсән Фәтхетдиновның музее кайда урнашкан?
а) Чирмешәндә;
б) Казанда;
в) Түбән Камада.

2 «Иң мөһиме – үз-үзеңезне алдамагыз». Бу сүзләрне кем әйткән?
а) Фёдор Достоевский;
б) Фёдор Абрамов;
в) Фёдор Тютчев.

3 2010 елда Исландиядә зур вулкан атылып, бик күп очкычлар маршрутларын үзгәртергә мәҗбүр булды. Вулканның атамасын дөрес әйтә алырсыз микән?
а) Эйядьяфлайёкюдль;
б) Эйяфьядлайёкюдль;
в) Эйяфьядлакоюдль.

4 «Кенотаф» сүзе нәрсәне аңлата?
а) бөтән кәмәргә ярамый торган ябык зират;
б) мәет җирләнмәгән урынга куелган кабер ташы;
в) җәсәдне крематорийга әзерләү җайланмасы.

Җаваплар: 1. в); 2. а); 3. б); 4. б).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15337 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 366

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+